ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ТЕЛЕ:
# ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

Казан
2021

**УДК 811.512.145**
**ББК 81.2(2=632.3)**
**Т 12**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы тәкъдиме буенча басыла*

**Җаваплы мөхәррир**
*филология фәннәре кандидаты **Ә.К. Булатова***

**Хезмәтне әзерләүчеләр:**
*филология фәннәре кандидаты **Р.Г. Галиуллин,***
*филология фәннәре кандидаты **Г.К. Һадиева***

**Т 12** **Татар теле: үткәне һәм бүгенгесе** / хезмәтне әзерләүчеләр: Р.Г. Галиуллин, Г.К. Һадиева. – Казан, 2021. – 72 б.
ISBN 978-5-93091-369-9

Әлеге хезмәттә татар теле, аның структурасы, язмачылык тарихы, мәгариф өлкәсендә телне укыту, әдәби тел һәм диалектларның керешүе, татар теле нормалары һәм телне саклау һ.б. мәсьәләләр һәркемгә аңлаешлы формада бәян ителә.

Китап киң катлау укучыларга һәм гомумән татар теленең үткәне һәм хәзерге торышы белән кызыксынучыларга адреслана.

УДК 811.512.145
ББК81.2(2=632.3)

**ISBN 978-5-93091-369-9**

© ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2021

## КЕРЕШ

Татарлар – бай тарихлы, югары мәдәнияткә ия халык. Аның үзгәлеген һәм кыйммәтен киң тарихи мәйданда караганда гына аңларга мөмкин. Татар мәдәнияте географик һәм тарихи яктан Евразия цивилизациясенә карый, шул ук вакытта Шәрыкта – Көнбатыш дөньясының, Көнбатышта Шәрык дөньясының бер өлеше булып кабул ителә. Үзәк Азиядә барлыкка килгән төрки мәдәният Урта гасырларда бөтен континентка диярлек тарала. Идел буе әлеге төрки-мөселман мәдәни системасында үзәк урынны били. Бүгенге көндә дә татар халкы – төрки-мөселман дөньясын берләштереп торган төп көчләрнең берсе.

Тарихына бәйле рәвештә, татар халкы дөнья күләмендә төрле тарафларга, илләргә сибелеп урнашкан. Бүгенге көндә дөньяда якынча 8 миллион татар кешесе яши дип исәпләнә[1]. Россия Федерациясендә сан буенча икенче урында торган халыкның төп өлеше күп гасырлар дәвамында үзенең тарихи Ватаны – Идел буенда, Уралда, Россия Федерациясенең Үзәк өлешендә, Себердә гомер кичерә. Язмышның катлаулы сынаулары аша үтеп, татар халкы үзенең милли һәм тарихи үзаңын, гореф-гадәтләрен һәм үзенчәлекле яшәешен саклап килә.

Рус халкы белән бергә татарлар Россия дәүләте формалашуның чишмә башында тора, бүген дә илнең икътисади-мәдәни үсешенә саллы өлеш кертүен дәвам итә.

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның 1913 елда язылган «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» шигырендәге:

---

[1] http://tatar-congress.org/ru/yanalyklar/vasil-shayhraziev-nasha-zadacha-obedinyat-i-pooshryat-vse-8-millionov-tatar

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без... –

дигән юллар бүген дә актуаль яңгырый.

2010 елгы Бөтенроссия халык санын алу мәгълүматлары буенча, Россия Федерациясендә 5 миллион 319 мең 877 татар кешесе яши[1]. Татарлар Россиядә яшәүчеләрнең 3,7% ын тәшкил итә. 1989 һәм 2002 еллардагы халык санын исәпкә алу барышында, татарлар 5,52 миллион кешедән 5,53 миллионга арткан булса, 2002 һәм 2010 елларда халык санын алу аралыгында 244 мең кешегә кимегән.

Россия Федерациясендәге татарларның төп өлеше Татарстан Республикасында яши (барлыгы 2012571 кеше, республика халкының гомуми санынннан 53,2%).

Россия Федерациясенең түбәндәге субъектларында татарлар аеруча күп: Башкортстан Республикасы (1009295), Чиләбе өлкәсе (180913), Ульяновск өлкәсе (155873), Оренбург өлкәсе (151482), Мәскәү шәһәре (149043), Свердловск өлкәсе (143803), Самара өлкәсе (126124), Пермь крае (115544), Ханты-Манси автономияле округы – Югра (108899), Төмән өлкәсе (102587), Удмуртия Республикасы (98831), Пенза өлкәсе (86431), Әстерхан өлкәсе (60523), Мәскәү өлкәсе (56202), Саратов өлкәсе (52884), Түбән Новгород өлкәсе (44103), Мордовия Республикасы (43392), Кырым Республикасы (42254), Омск өлкәсе (41870), Кемерово өлкәсе (40229), Марий Эл Республикасы (38357), Киров өлкәсе (36457), Красноярск крае (34828), Чувашия Республикасы (34214), Санкт-Петербург шәһәре (30857), Ямал-Ненец автономияле округы (28509), Краснодар крае (24840), Волгоград өлкәсе (24557), Новосибирск өлкәсе (24158), Иркутск өлкәсе (22882), Томск өлкәсе (17029), Курган өлкәсе (17017), Ростов өлкәсе (13948), Ставрополь крае (11795), Коми Республикасы (10779), Приморье крае (10640) һ.б.[2]

Мәгълүм булганча, һәр халыкның яшәү асылын, гореф-гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, гомумән, рухи-мәдәни хә-

[1] http://www.gks.ru/free_doc/new_site/perepis2010/perepis_itogi1612.htm

[2] http://www.gks.ru/free_doc/new_site/population/demo/perepis_krim/perepis_krim.html

зинәсен күп гасырлар буена үзенә туплаган төп байлык – ул аның теле.

Бүгенге көндә тел проблемасы дөнья күләмендә иң мөһим мәсьәләләрдән исәпләнә. Берләшкән Милләтләр Оешмасы глобальләшү шартларында күп кенә телләрнең югалуына һәрвакыт борчылуын белдереп килә. БМОның Генераль Ассамблеясы 2019 елны Халыкара асаба халыклар телләре елы дип игълан итеп, андый телләрнең 5–6 мең калуын белдерде. ЮНЕСКОның рәсми чыганаклары буенча, дөньяда 6700 тел барлыгы әйтелә[1].

Иң зур тел каталогларының берсе булган Ethnologue мәгълүматлары буенча[2], дөньядагы телләрнең якынча 41 % ына югалу куркынычы яный. Кытай, инглиз, һинд, испан, рус һәм гарәп телләре исә иң таралган телләр булып исәпләнә.

Татар теле – Татарстан Республикасында милләт һәм дәүләт теле. Россия Федерациясендә таралышы һәм сөйләшүчеләр саны буенча икенче урында тора. Ул төрки телләргә карый, монгол һәм тунгус-маньчжур телләре белән бергә алтай телләре төркеменә керә. Татар теле төрки телләрнең кыпчак (*башкорт, казакъ, караим, карачай-балкар, кумык, кыргыз, нугай телләре* һ.б.) группасына карый.

Татар теле хәзерге татар милләте белән бергә формалаша һәм бер төркем (лексик, фонетик, синтаксик һ.б.) үзенчәлекләргә ия булып, Идел буе – Урал – Себер татарлары сөйләшләрен бергә туплый һәм башка төрки телләрдән аерып куя. Үзенең тарихи үсешендә татар теле күрше халыклар – төрки (башкорт, чуваш), фин-угор (мари, мордва, удмурт һ.б.), славян (рус) телләре, бигрәк тә иран телләре йогынтысын тоя. Урта гасырларда ул гарәп һәм фарсы телләре (дин, мәгариф һәм мәдәниятнең башка өлкәләрендәге терминология) тәэсирендә үзгәрешләр кичерә. Хәзерге татар әдәби теле үзенең диалектлары нигезендә формалаша. Татар әдәби теленең тамырлары төрки рун язмаларына барып тоташа. Татар халкы язмачылыгының ике мең еллык тарихы бар[3].

---

[1] https://news.un.org/ru/story/2019/02/1348292

[2] https://www.ethnologue.com/guides/how-many-languages-endangered

[3] Татар дөньясы=Татарский мир / авт.-төз.: Г.Ф. Габдрахманова, Э.М. Галимова, Д.Ф. Заһидуллина, И.Л. Измайлов, А.Р. Салихова, А.Г. Ситдыйков, Л.М. Шкляева. Казан: «Заман» нәшрияты, 2019. Б. 127–128.

Тел – халыкның җаны да, аның тормышы да; халыкның туган җиргә, мәдәнияткә, дингә, төрле ышануларга мәхәббәтен үзенә сыйдыра. Ул татар халкының асыл мирасы, борынгы һәм заманча кыйммәте булып тора.

Күренекле татар язучысы, төрки-мөселман дөньясының танылган җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, хокук белгече Садри Максудиның милләт язмышында телнең урыны турында әйткән сүзләре һичкайчан әһәмиятен югалтмаячак: *«Телебезне өйрәнми башлаган көннән башлап без бетә башлаячакбыз. Безнең бер милләт булып тора алуыбыз телебезне саклый алуыбызга бәйледер. Телебезне саклый алсак, бер милләт булып тора алырбыз, әгәр телебезне саклый алмасак, милләтебездән мәхрүм булырбыз»*.

Әлеге китап киң катлау укучыларны татар теле структурасы һәм аңа хас үзенчәлекләр белән мөмкин кадәр гади һәм аңлаешлы итеп таныштыру максатыннан эшләнелде. Телебезнең әдәби тел буларак формалашуы, язмачылыгы барлыкка килү, диалектлары, татар теленең тел нормалары, әлеге нормаларны билгеләүче сүзлекләр турында гомуми мәгълүмат китерелде. Шулай ук татарларда мәгариф системасы һәм галимнәрнең тел белеме өлкәсендәге эшчәнлегенә, бүгенге көндә телне саклау мәсьәләсенә кыскача күзәтү ясалды. Тел белеменең аерым мәсьәләләре турында филология фәннәре кандидатлары Р.Ф. Мирхәев, Р.Т. Сәфәров, О.Р. Хисамов, А.Я. Хөсәинова язды.

# I БҮЛЕК
# ТАТАРЛАРДА ЯЗУ ҺӘМ ӘДӘБИ ТЕЛ ТАРИХЫ

## Татарларда язу тарихы

Татарлар күп гасырлык язу тарихына ия. Галимнәр фикеренчә, аларның ерак бабалары башта борынгы төрки рун һәм иске уйгур язуыннан файдаланганнар, ә ислам динен кабул иткәннән соң, гарәп язуына күчкәннәр. Мең ел дәвамында гамәлдә булган гарәп язуы XX гасырның 20 нче елларында латин, ә берникадәр вакыттан соң анысы кирилл язуы белән алыштырылган.

Фәндә борынгы төрки рун язуының барлыкка килү вакыты һәм географик яктан таралыш ареалы Себер һәм Үзәк Азия җирләрендә оешкан Борынгы төрки каганат (VI–X гасырлар) белән бәйләп карала. Шул ук вакытта аның күпкә иртәрәк уйлап табылганлыгы турында да фикерләр әйтелә. Бер төркем галимнәр борынгы төрки руннары пиктографик билгеләрдән барлыкка килгән дип саныйлар. Алар мондый билгеләргә үрнәк итеп күчмә кабиләләрдә билгеле бер ыруга, яисә нәселгә беркетелгән һәм буыннан буынга тапшырылып килгән тамгаларны китерәләр. Ләкин күпчелек белгечләр әлеге язуны төркиләр үзләренең күршеләре согыдлардан кабул иткәннәр һәм ул үзенең тамырлары белән Якын Көнчыгышка барып тоташа дигән фикерне алга сөрәләр.

Борынгы төрки *рун язуы* 35 тамгадан тора. Алар бер-берсе белән кушылмыйча уңнан сулга язылганнар. Әлеге язу үрнәкләренең күпчелеген борынгы төркиләрнең яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, дөньяны күзаллаулары, дәүләтчелек тарихы, башка халыклар белән үзара бәйләнешләре турында мәгълүматлар чагылыш тапкан кабер ташъязмалары тәшкил итә.



Рун язуы тамгалары

VIII–X гасырларда борынгы төрки рун язуы хәзерге Монголия, Көньяк Себер, Көнчыгыш Төркестан, Урта Азия, Казакъстан, Идел буе, Төньяк Кавказ һәм Көнчыгыш Европа җирләрендә көн күргән төркиләр арасында киң таралган була. Идел-Урал буйларына да ул борынгы төрки кабиләләр белән бергә үтеп кергән дип санала. Аның бу җирләрдә кулланылганлыгы археологик материаллар белән раслана.

Татарларның борынгы бабалары рун язуы белән беррәттән *иске уйгур* язуыннан да файдаланганнар. Уйгурлар – Үзәк Азиядә көн күргән борынгы халыкларның берсе. VIII–IX гасырларда алар үзләренең беренче дәүләтләрен төзиләр, соңрак Караханлылар (IX–XIII гасырлар), Алтын Урда (XIII–XV гасырлар) дәүләтләренең идарә һәм мәгариф эшләрендә мөһим роль уйныйлар.

Галимнәр фикеренчә, иске уйгур язуы да үзенең тамырлары белән борынгы согыд язуына барып тоташа. Күпчелек хәрефләрнең язылу шәкеле аларның сүздә кайсы урында (башта, уртада һәм ахырда) килүенә бәйле рәвештә үзгәрә. Алар өстән аска таба язылганнар. Иске уйгур язуында иҗат ителгән әсәрләрнең күбесен дини, фәлсәфи, әдәби һәм юридик текстлар тәшкил итә. Идел-Урал төбәгендә әлеге язу Алтын Урда чорында хан сараенда рәсми документлар һәм хатлар төзегәндә кулланылган.




Иске уйгур алфавиты

Алга таба рун һәм иске уйгур язуын *гарәп язуы* алыштырган. Идел болгарлары әлеге язуны ислам дине белән бергә кабул итә. 28 хәрефтән торган гарәп алфавитында 25 хәреф – тартык, 3 хәреф сузык авазны белдерә. Хәрәкәләр белән кыска сузыклар күрсәтелә. Хәрефләр, аерым, сүз башында, сүз уртасында һәм сүз ахырында килүләренә карап, ике яисә дүрт шәкелдә уңнан сулга языла-лар. Фарсылар тарафыннан гарәп язуына, [п], [ч] һәм [ң] тартык авазларын бирү өчен, тагын өч хәреф өстәлгән. Әлеге вариантта ул татарлар тарафыннан XIX гасыр ахырына кадәр бернинди үзгәртүләрсез кулланыла. Тарихта ул «Иске имла» («Иске орфография») исеме белән билгеле. Аның ярдәмендә татар халкының мең еллык бай язма мирасы иҗат ителгән.




Иске имла алфавиты

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында татарлар арасында имла төзәтү хәрәкәте көчәя. Бу чорда әлифба китапларына татар теленең моңарчы язуда чагылыш тапмаган сузык авазлары өчен аерым хәрефләр кертелә башлый. Октябрь революциясеннән соң язу мәсьәләсе дәүләт дәрәҗәсенә күтәрелә: 1920 елның 19 декабрендә ТАССР Халык Комиссарлары Советы карары белән гарәп графикасына нигезләнгән татар язуының яңартылган варианты раслана. Ул «Яңа имла» («Яңа орфография») дип атала һәм татар телендә латин графикасын кабул иткәнгә кадәр кулланылышта була.

Гарәп хәрефләренең төрки телләрнең фонетик үзенчәлекләрен язуда тулысынча чагылдыра алмавы һәм аны башка алфавит белән алыштыру зарурлыгы турындагы фикерне төрки зыялылар арасында беренчеләрдән булып XIX йөз урталарында бөек азәрбайҗан язучысы һәм драматургы Мирза Фатали Ахундов күтәреп чыга. Татарларда латинчылык хәрәкәтенең башында шагыйрь Сәгыйть Рәмиев тора. 1908–1909 елларда ул үз әсәрләрен латин хәрефләрен кулланып яза башлый һәм татар теле өчен әлеге графика нигезендә алфавит проектын төзи, ләкин соңгысы бу чорда киң җәмәгатьчелектә яклау тапмый.



1920–1930 елларда гамәлдә булган латин алвавиты

СССР җирлегендә яшәүче төрки халыкларда латин язуына күчү мәсьәләсе Октябрь инкыйлабыннан соң яңадан күтәрелә. Бу чорда татар дөньясында аңа багышлап күпсанлы оештыру, фәнни һәм матбугат чаралары уздырыла, алфавит проектлары эшләнә. Нәтиҗәдә 1927 елның 3 июлендә ТАССР Халык Комиссарлары Советы үзенең махсус карары белән латин графикасы нигезендәге «Яңалиф» алфавитын татар теленең рәсми алфавиты дип игълан итә. Ул кирилл графикасы нигезендә яңа алфавит кабул ителгәнгә кадәр 12 ел дәвамында кулланыла.

Татар теле авазларын язуда кирилл графикасы ярдәмендә бирүнең беренче тәҗрибәләре XIX гасыр урталарына карый. Бу чорда профессор Н.И. Ильминский үзенең фикердәшләре белән татар теле өчен кирилл графикасы нигезендә беренче алфавитны төзи. Ләкин әлеге эшнең асылында мөселман халыклары арасында христиан динен тарату омтылышы ятканлыктан, татарлар аны кулланудан баш тарталар һәм ул керәшен татарлары арасында гына таралыш ала.

Совет илендә яшәүче халыкларның язуын кирилл графикасына күчерү мәсьәләсе XX гасырның 30 нчы елларында күтәрелә, һәм

аның кирәклеге рус теленнән кергән сүзләрне аның үзендәгечә язарга, рус һәм туган телләрне өйрәнгәндә төрле язу системаларын үзләштерүдән котылырга мөмкинлек бирүе белән аңлатыла. Татарларда яңа алфавит һәм орфография 1939 елның 5 маенда рәсми рәвештә гамәлгә куела. Кулланылыш барышында кертелгән кайбер орфографик аныклаулар 1941 елның 10 гыйнварында раслана. Ләкин кирилл графикасы нигезендәге татар язуын камилләштерү омтылышлары моның белән генә тәмамланмый. 1955 елда яңа орфография проекты төзелә. Ул 1958 елны киң җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителә, әмма хөкүмәт комиссиясе аны, җитешсезлекләре булу сәбәпле, гамәлгә ашырырлык дип тапмый. 1989 елны ТАССР Югары Советы Президиумы указы белән татар алфавитына [қ], [ғ] һәм [w] авазлары өчен махсус хәрефләр өстәлә, ләкин алар практик кулланылышта чагылыш тапмыйлар.

XX гасырның 90 нчы елларында татар җәмәгатьчелеге арасында кабат латинга күчү мәсьәләсе күтәрелә. Күпсанлы бәхәсләрдән соң, 1999 елда ТР Дәүләт Советы «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Закон кабул итә. Әлеге канун нигезендә мәгариф, мәдәният, матбугат, нәшрият өлкәләрендә күпмедер гамәли эшләр башкарыла: белем бирү оешмалары өчен дәреслек, кулланмалар әзерләнә, махсус рубрикалар булдырыла, дистәләгән китап нәшер ителә. Әмма 2002 елда Дәүләт Думасы тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә кириллицадан кала башка язу системасына нигезләнгән алфавитларны рәсми рәвештә куллануны тыя торган канун кабул ителү сәбәпле, ул кулланылышка кертелми кала.

Кирилл нигезендәге татар алфавитында хәрефләрнең урнашу тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1997 елның гыйнвар карары белән үзгәртелә. Нәтиҗәдә ул түбәндәге рәвешкә керә: Аа Әә Бб Вв Гг Дд Ее Ёё Жж Җҗ Зз Ии Йй Кк Лл Мм Нн ң Оо Өө Пп Рр Сс Тт Уу Үү Фф Хх Һһ Цц Чч Шш Щщ ъ Ыы ь Ээ Юю Яя.

## Татарларда әдәби тел тарихы

Әдәби тел тарихы аерым бер чорда яшәгән дәүләттәге, билгеле бер графика белән язылган конкрет әсәрнең теленә нигезләнеп өйрәнелә башлый. Татар теленең төрки гаиләдә язма традициясе VI–

VIII гасырлардан килә, язма истәлекнең язылу датасы XI (Болгар кабер ташларындагы текстлар) – XIII (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы) гасырларга барып тоташа.

Татар язма әдәби теле борынгы гомуми төрки язма әдәби теле (V–X гасырлар), иске гомуми төрки язма әдәби теле (XI–XIX гасырлар), иске татар язма әдәби теле (XVI–XIX гасырлар) һәм татар милли язма әдәби теленә (XIX гасырның икенче яртысыннан башлап хәзергә кадәр) бүлеп карала.

Иң борынгы төрки язмачылык, галимнәр күрсәтүенчә, VI–VII гасырларда Алтай, Көнбатыш Себер һәм Төньяк Монголия җирләрендә яшәгән Төрки каганат дәверендәге рун язмаларына барып тоташа. Фәнни әдәбиятта алар Орхон-Енисей язмалары дип атала. Алар шул чорда яшәгән төрле төрки кабиләләрнең телләрен һәм диалектларын үзләренә берләштергәннәр һәм, башлыча, угыз-уйгур телләре нигезендә формалашкан уртак әдәби телдә язылганнар. Шуңа күрә Орхон-Енисей язмалары фәндә хәзерге төрки халыкларның иң борынгы уртак мираслары дип карала.

Идел-Урал төбәгенә рун язуы төрки-болгар ыруларына ияреп килә, монда XII гасырга кадәр кулланыла. Төрки рун язуының иң билгеле истәлекләре Орхон-Енисей ташъязмалары исеме белән тарихка кергән. Алар арасында Билге каган һәм Күлтәгин (732–735), Икенче Төрки каганатның беренче каганнарына киңәшче булган Төньюкук (ташбилге 716 елдан соң, үзе исән вакытта ук корылган) хөрмәтенә куелганнары – иң күләмлеләрдән. Алар Төрки дәүләтләр тарихы, галәм, кешенең барлыкка килүе турындагы күзаллау фонында геройларның тормышын, каһарманлыгын сөйлиләр. Вакыйгалар Билге каган ташъязмасында өстән-өстән генә әйтеп кителсә, Күлтәгин язмасында тулырак чагыла, ә инде Төньюкук язмасында шактый детальләп тасвирлана. «Төрки язма әдәбиятның иң борынгы идеологик җирлеге, әлбәттә, бөтен халык дине функциясен үтәгән тәңречелек һәм халык мифологиясе булган»[1], – дип билгеләп үтә М. Бакиров.

Кәгазьгә төшерелгән рун язулы текст – «Ырык битиг» («Ырым язуы», X гасырның беренче яртысы) дүртьюллык шигырьләр формасында. Борынгы уйгур язуындагы (текстта ул төрки язу дип ата-

[1] *Бакиров М.Х.* Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 190.

ла) «Алтын ярук» китабы халыкның һәм кешенең тормышындагы хокукый мәсьәләләргә кагыла. Әлеге үгет-нәсыйхәт китабы буддизмга бәйләнешле хикәятләрне үз эченә ала.

Рун һәм уйгур язуларындагы текстлар төрле төрки кабиләләр кулланган уртак әдәби телдә язылганнар.

X гасырда төркиләрнең зур дәүләтләре оеша. Шул чорда бүгенгә кадәр сакланып килгән иң күренекле әсәрләр – Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» (1072–1083) сүзлеге, Йосыф Баласагунның «Котадгу билиг» (1069–1070) поэмалары языла. Алар төрки кабиләләрнең мәдәни потенциалын күрсәтә.

«Диване лөгатет-төрк» сүзлеге (аны татарчага «Төрки телләр сүзлеге», «Төрки телләр җыентыгы» дип тәрҗемә итәргә мөмкин) – үзенең төп асылы белән лексикографик хезмәт. Анда М. Кашгари үз дәверендәге күпсанлы төрки кабилә телләрендә кулланылышта булган 9 мең чамасы сүз һәм сүз тезмәсе китереп, аларның мәгънәләрен аңлата. Моннан тыш, автор төрки телләрнең фонетикасы һәм грамматикасы турында күптөрле мәгълүматлар бирә, фонетик-морфологик билгеләренә карап, төрки телләрне көнчыгыш һәм көнбатыш төркемнәргә аера. Бу исә төрки телләрне классификацияләүдә беренче уңышлы тәҗрибә булып тора. XI йөздәге төрки дөньяның дәүләти, сәяси, иҗтимагый, икътисади һәм мәдәни тормышы тәфсилле яктыртылганлыктан, ул әдәбият белгечләре, фольклорчылар, тарихчылар, этнографлар өчен дә кызыклы хезмәт булып тора.

Йосыф Баласагунның «Котадгу билиг» поэмасы – Борынгы һәм Урта гасырлар төрки дөньясында төрки халыкларның иң танылган уртак әсәре. Жанр табигате белән синкретик рухлы фәлсәфи-дидактик әсәрдә тормыш тәҗрибәсе, инсан хакында уй-фикерләр тупланган.

922 елда Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгәннән башлап XX гасырның беренче чирегенә кадәр болгар-татарлар гарәп графикасыннан файдалана. Гарәп һәм фарсы алынмаларының язылышы катгый рәвештә үз чыганак теленең кагыйдәсенә нигезләнеп бара. Гарәп графикасы рәсми документларда һәм дәүләт эш кәгазьләрендә, әдәби әсәрләрдә яши һәм камилләшә.

Урта гасырлар төрки-татар әдәбияты канунчылык һәм гарәп һәм фарсы әдәбиятлары жанрлары кысаларында үсә-үзгәрә. Ул

Коръән буенча бер илаһлык фәлсәфәсе – әт-Тәүхидкә йөз тота. Әдәбиятта дини-суфичыл дөнья сурәте хөкем сөрә. Бу чорның иң күренекле әсәре булып Кол Галинең (1183–1233 һәм 1240 еллар тирәсендә яшәгән дип фаразлана) болгар-кыпчак телендә угыз элементларын файдаланып язылган «Кыйссаи Йосыф» (1233) романтик поэмасы санала. Коръәни сюжет заманча образларда үстерелеш таба. Поэма татарлар арасында киң таралган була, татар әдәби теле формалашуда әһәмиятле роль уйный. Аның нөсхәләре Казан, Санкт-Петербург, шулай ук Берлин, Братислава, Дрезден, Вена китапханәләрендә саклана.

Йосыф турындагы кыйссаның үзәген дөнья әдәбияты бик тә үз иткән ике тема, ике мотив тәшкил итә. Аларның беренчесе – аталар һәм балалар арасындагы конфликт, икенчесе – Зөләйханың гүзәл Йосыфка эчке һәм тышкы каршылыклар белән тулы дәртле һәм шашкын мәхәббәте. Йосыф китабында шушы ике теманы, ике сюжет сызыгын үзара бәйләгән дөньяга фәлсәфи-этик карашлар системасы бар. Ул – Коръән тәгълиматының умыртка баганасын тәшкил иткән, Аллаһның бердәнберлеген раслаган, Мөхәммәд пәйгамбәрне аның җир йөзендәге илчесе дип санаган «Лә иләһә илләллаһ Мөхәммәдер рәсүлуллаһ» гыйбарәсе белән белдерелгән әт-Тәүхид фәлсәфәсе. Ислам диненең асылын, рухи хәзинәсен тәшкил иткән бу хактагы карашлар әсәрдә иң элек Аллаһы Тәгаләнең гүзәл һәм тирән мәгънәле исемнәрендә чагылыш таба[1]. Өч тел традициясенә – карахани-уйгур, угыз һәм кыпчак телләре катнашмасына таянып иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» үзеннән соң язылган төрки әдәбиятның күп кенә күренекле әсәрләренә тел ягыннан да, фәлсәфи-сәнгатьчә яңгыраш ягыннан да гасырлар дәвамында йогынты ясаган.

Урта гасырлардагы язмачылык һәм әдәбият үсеше XIII гасырның икенче яртысы – XV гасырның беренче яртысындагы шәһәр мәдәнияте (угыз-кыпчак тибы), Алтын Урда (иске татар теле) теле нигезендә һәм төрки-рун, карахани-уйгур традицияләрендә формалашкан Идел буе төрки теле белән бәйләнгән.

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар / фәнни мөх. М.Х. Бакиров. Б. 215.

XIII гасыр урталарында, монгол яуларыннан соң, киң территориядәге Дәште Кыпчак җирләрендә башкаласы Сарай шәһәре булган Алтын Урда дәүләте оеша. Идел Болгары һәм Харәзем дәүләтләренең уңай традицияләре нигезендә ул көчле икътисади, сәяси һәм мәдәни үзәк буларак яшәеш ала.

Халкыбызның бай тарихында ике гасырга якын чорны үз эченә алган, XIII йөзнең икенче яртысы – XV йөзнең беренче яртысына кадәр яшәгән Алтын Урда дәүләтенең язма теле, асылда, X–XIII йөзнең беренче яртысына кадәрге Идел Болгары дәүләтендәге төрки-болгар, ягъни карахани-уйгур (дөресрәге, харәзем-төрки) нигезгә көньяк-угыз һәм төньяк-кыпчак (Идел буе-татар) элементлары кушылган әдәби телнең дәвамы була[1]. Шулай ук гарәп, фарсы, рус, латин, грек, фин-угор һәм кайбер башка телләр дә теге яки бу дәрәҗәдә кулланылган. Аеруча гарәп һәм фарсы телләрен белү зур дәрәҗә саналган.

Бу чорда төрки телдәге матур әдәбият һәм рәсми документлар гарәп язуында иҗат ителә, XIV йөздә ул рәсми статус ала. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1342), Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» (1391), Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353) әсәрләре чор әдәби мирасының үзәген тәшкил итә һәм төрки-татарлар сүз сәнгатенең югары дәрәҗәгә ирешүе хакында сөйли. Шагыйрьләр яшәеш нигезләре, яшәү мәгънәсе, хөкемдарлар һәм халык арасындагы мөнәсәбәтләр, әхлак, яшәү һәм үлем, мәхәббәт мәсьәләләрен күтәрәләр. Текстларда дини, фәлсәфи, этик, космогоник материаллар урын ала.

Шушы чорда татарларда дини-дидактик әдәбият формалашып җитә: Коръән һәм Хәдисләр нигезендә – беренче тәфсирләр һәм Мөхәммәд пәйгамбәр тормышы турында сөйли торган «сиратен-нәби»ләр материалында дини-дидактик әсәрләр языла: Рабгузиның «Кыйссас әл-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы», 1310), Мәхмүд Болгариның «Нәһҗ әл-фәрадис»е («Оҗмахка ачык юл», 1358), Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан»ы, «Кисекбаш китабы» һ.б. Мондый текстлар бертөрле композициягә корыла: дини яки әхлакый фикерләр ниндидер тарихлар ярдәмендә иллюстрацияләнә. Сюжетлар исә тамырлары белән гарәп яки фарсы

[1] *Тенишев Э.Р.* О языке поэмы «Кыссаи Йусуф» Кул Гали // Поэт гуманист К. Гали. Казань, 1987. С.135–137.

чыганакларына барып тоташа, аларда дөнья сурәте җир тормышы һәм теге дөнья киселешендә булып чыга. Татарларның әдәби тел нормалары һәм стильләре татар ханлыклары чорында формалашып җитә. Алар халык теле нигезендә төрле әдәби-сурәтләү чаралары белән байый һәм төрләләнә[1].

Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» поэмалары фарсы классиклары Низами һәм Сәгъди әсәрләренә мөнәсәбәттә туган.

Котб мөрәҗәгать иткән Хөсрәү-Ширин сюжеты – Шәрык дөньясында киң таралган мәхәббәт тарихларының берсе. Әсәрдә Алтын Урда, Идел-йорт, төрки-татар яшәеше белән турыдан-туры бәйләнешле хәл-вакыйгалар байтак.

«Котб» тәхәллүсенең Идел йорттагы шәһәргә нисбәтән алынуы хакыйкатькә шулай да якын. Әсәр телендәге аерым сүзләр һәм формалар да (*төн ката; сала; камгак; баргым; кайтмага* һ.б.) бу карашны куәтли. Аерым галимнәр фикеренчә, «Хөсрәү вә Ширин»дә татар теленең хәзерге Пенза, Мордовия төбәгенә хас шивә элементлары ныграк гәүдәләнеш тапкан. Котоба каласы да нәкъ шул җирләргә нисбәт ителә»[2]. Гомумән алганда, «Хөсрәү вә Ширин» Алтын Урда әдәби теле үсешендә мөһим роль уйный.

Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» («Төркичә Гөлестан китабы») Сәгъдинең фарсы телендәге «Гөлестан» әсәренә (1258) нигезләнеп язылган. Ул шигырь белән аралаштырылып, рифмалы проза белән иҗат ителгән чагыштырмача мөстәкыйль хикәяләр тупламыннан гыйбарәт. Әсәр Мисыр солтаны Заһир Сәйфеддин Бәркук сараендагы олуг вәзир вазифаларын башкаручы әмир Бәтхаска (Тәйхаска) багышланган.

Урта гасырлар әдәби ядкярләренең күпчелеге кебек, Сәгъди әсәре дә гарәпчә, фарсыча һәм башка телләрдәге материалларны, сюжет-мотивларны, образларны мул куллану нәтиҗәсендә туган. «Гөлестан»да аеруча Коръәннән өзекләр, гарәпчә хәдисләр күп.

---

[1] Татар дөньясы=Татарский мир / авт.-төз.: Г.Ф. Габдрахманова, Э.М. Галимова, Д.Ф. Заһидуллина, И.Л. Измайлов, А.Р. Салихова, А.Г. Ситдыйков, Л.М. Шкляева. Казан: Заман, 2019. Б. 132–133.

[2] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар / фәнни мөх. М.Х. Бакиров. Б. 280.

Алар, нигездә, Сәйф Сараи әсәренә дә күчерелгән. «Гөлестан бит-төрки» авторы бу изге текстларның шактыен төркичәгә тәрҗемә итеп тә бирә; ә бер өлешен бернинди шәрехсез гарәп телендә генә тәкъдим итә[1].

XV гасыр урталарында, Алтын Урда таркалгач, бер-берсенә бәйсез ханлыклар оеша. Казан ханлыгы исә, турыдан-туры Идел буе Болгар дәүләтенең варисы булган хәлдә, XV йөзнең икенче яртысы – XVI гасырларда икътисади яктан алга киткән дәүләтләрнең берсе булган.

Казан ханлыгы дәвере мөстәкыйль милли әдәбиятлар формалашу чорын башлап җибәрә. Татарларда бай язмачылык, дипломатия язмалары булу хакында мәгълүматлар сакланып калган. Алар ярлыкларны, фәрманнарны, дидактик трактатларны, хәтта, «Коръән тәфсире», гарәпчә-татарча сүзлекчәне дә үз эченә ала. Бу чорга аноним авторның мөселман юриспруденциясе һәм әхлагының кайбер мәсьәләләре шәрехләнгән «Нәсыйхәтес-салихин» («Игелекле кешеләр нәсыйхәте» трактаты карый. Әднәш Хафиз 1554 елда «Сираҗ әл-кулүб» («Йөрәкләр яктысы») дигән дидактик җыентык төзи.

Күренекле шагыйрь, сәед һәм дипломат Колшәриф (1552 елда Казан өчен сугышта һәлак була), Казан ханы Мөхәммәдәмин (1487–1496, 1502–1518 елларда тәхеттә утыра), Гарифбәк һәм Мөхәммәд Шәриф, Өмми Камал (1475 елда үлә) – бу чорның күренекле суфи шагыйрьләре.

XV–XVI гасырларда иске татар әдәби телен башка төрки әдәби телләрдән аерып торган лексик, фонетик һәм грамматик нормалар калыплаша, язма сөйләм җирле диалектлар хисабына байый. Телнең вазифалары киңәя – анда фәнни әдәбият, публицистика иҗат ителә, ул рәсми һәм шәхси язышуларда, эш кәгазьләрендә файдаланыла һ.б. Татар теле рус мәдәнияте үсешенә дә йогынты ясый, моңа мисал итеп өлешчә татарча иҗат ителгән Афанасий Никитин текстын китерергә мөмкин. Гарәп язулы текстлар рус елъязмаларында да очрый. Бу чорда гарәп язулы татар

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар / фәнни мөх. М.Х. Бакиров. Б. 312–313.

теле Евразиягә мәгълүмат тапшыруның универсаль чарасы булып хезмәт итә[1].

Әлеге чорның күренекле вәкиле шагыйрь Мөхәммәдьяр (якынча 1497–1552) ике зур әсәр – «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге», 1540) һәм «Нуры содур» («Күңелләр нуры», 1542) поэмаларын иҗат итә, аларда дини-дидактик фикерләр үзәктә тора.

«Төхфәи мәрдан» тормыш һәм табигать күренешләрен, шагыйрьнең кичерешләрен сурәтләгән парчаларны, әхлакый һәм фәлсәфи хөкем, гыйбрәтләрне, шуларны раслау өчен китерелгән хикәятләрне үз эченә ала. Шул заман әдәбиятының гадәти алымы буенча, башта Аллаһ һәм пәйгамбәрне зурлаганнан соң, Мөхәммәдьяр, тирән кайгыга бирелеп, үзенең күңеле белән сөйләшә, шагыйрь булуның җаваплылыгы хакында фикер йөртә. Поэма Урта гасырлар әдәбиятында зур урын алган гуманизм мәсьәләләренә – гаделлекне мактауга, игелеккә һәм шәфкатькә өндәүгә, явызлык һәм җәбер-золымны гаепләүгә багышланган.

Казан ханлыгы җимерелгәч, гарәп язуы, рәсми вазифаларын югалтып, дин, мәгариф, мәдәният телендә саклана. Шуның белән бергә, гасырлар буена язу-уку, китаби язмачылык тарихы булган белемле татарлар яңа дәүләт таләп иткән вазифаларны үтәүгә, шул дәүләтнең мәнфәгатьләрен тормышка ашыру юнәлешендәге эшләргә тартыла. Россия хакимиятенә төрки телле халыклар белән аралашу өчен тылмачлар, писерләр, илчеләр кирәк була. Татар язма теле (иске татар теле) Көнчыгыш илләре белән аралашуда XVI–XIX гасыр башына кадәр, ягъни өч йөз еллар буена икенче функциональ дәүләт теле буларак файдаланыла. Рәсми эш кәгазьләре языла торган тел лексик составы, грамматик формалары белән татар халкының сөйләмә теленә якын булганга күрә, документларның теле «татар язуы» дип атала[2].

Россиядәге башка халыклар белән чагыштырганда, татарлар арасында грамоталык дәрәҗәсенең югары булуын да әйтергә кирәк. XVI гасыр татар әдәбиятында тарихи хроникалар һәм героик эпос активлашу күзәтелә. Шәех Ясәви карашлары тәэ-

---

[1] Татар дөньясы=Татарский мир / авт.-төз.: Г.Ф. Габдрахманова, Э.М. Галимова, Д.Ф. Заһидуллина, И.Л. Измайлов, А.Р. Салихова, А.Г. Ситдыйков, Л.М. Шкляева. Казан: «Заман» нәшрияты, 2019. Б. 133.

[2] *Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – нач. XVIII вв.) Казань, 1999. С. 7–14.

сирендә Ясәвия һәм Нәкышбәндия тарикатьләре киң тарала. Әдәбиятта аларның чагылышы Мәүла Колый, Габди, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки һ.б. иҗатында аермачык күренә. Суфи әдәбиятта тарикать юлына чыккан, камил инсан турындагы тәгълимат пәйда була. Бу үзенчәлек дини һәм дөньяви карашларның кисешүенә, әдәбиятка яңа образлар һәм метафоралар урнашуга китерә.

1708 елда «Казан патшалыгы» төшенчәсе юкка чыгарыла һәм күптөрле халыкларны үз эченә алган Казан губернасы игълан ителә[1]. Сәнәгать, икътисад өлкәсендәге, базар бәйләнешләрендәге хәрәкәт, Идел буе һәм Урал төбәгендәге халыкларның иҗтимагый аңы, мәдәнияте, мәгарифе үсешенә үзенчә тәэсир итә.

Болгар чоры (Болгар төркисе), Алтын Урда чорыннан килә торган кыпчак-татар язма теле (Алтын Урда төркисе), Казан ханлыгында иске татар теле (Казан төркисе) төбәктәге сөйләмә формалар белән кушылып, XVII–XVIII гасырларда, авторлар үзләре билдергәнчә, Болгар-Казан төркисе дип дәвам иттерелә. Бу чорда да әдәби тел гади халык сөйләменә якыная бара. Бу үзенчәлек юлъязмалар төсендәге күпсанлы сәяхәтнамәләрдә һәм хаҗнамәләрдә, эш кәгазьләрендә аермачык күренә.

Сәяхәтнамә жанрының беренче үрнәге Исмәгыйль Бикмөхәммәтов тарафыннан 1751 елда Һиндстанга сәяхәт турында языла. Әдәбиятта элеккеге традицион формалар, борынгы төрки тел элементлары белән янәшә чит тел (гарәп, фарсы) элементлары актив кулланыла.

XVIII гасыр башыннан татар мәдәниятендә дөньявилык чаткылары көчәя, тарихка, легендаларга нигезләнгән хикәятләр пәйда була. 1755–1756 елларда татар-башкорт баш күтәрүенең идеологы Батырша (Габдулла Галиев, 1715–1762) тарафыннан язылган «Гарызнамә» исә чорның тарихи вакыйгаларын чагылдыра. Пугачёв восстаниесе күренешләре «Казан алыну хикәяте»ндә күренә. Габди (1679 – XVIII гасырның беренче чиреге), Габдессәлам (1700–1767), Г. Мөслимов һ.б. әсәрләренең теле сөйләм телен хәтерләтә.

---

[1] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / фәнни мөх. Х.Й. Миңнегулов. 2014. Б. 267.

Татарларда китап басу тарихы XVIII йөз башына карый: 1722 елда императорның поход типографиясендә татар телендә Пётр I Манифесты дөнья күрә. 1778 елда Мәскәүдә күренекле педагог һәм тәрҗемәче Сәгыйть Хәлфинның руслар өчен татар әлифбасы – «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов» нәшер ителә. Россия империясе мөселманнарының күпсанлы мөрәҗәгатьләре буенча Екатерина II чорында Коръән бастыру хакында указ (1787) чыга. 1800 елда Казанда гарәп хәрефләре белән китап басу өчен Азия типографиясе оеша. Анда 1801–1829 елларда гомуми тиражы 280 мең данә булган 93 китап дөнья күрә. «Азия типографиясе» Казанда татар китабы бастыру өчен җирлек әзерли. Басма продукция исә Идел буе, Кавказ, Урта Азия, Себернең төрки-мөселман халыклары арасында тарала. Ул Кытай Төркестанына, шәркый Һиндстанга кадәр барып ирешә[1].

XVIII гасыр ахырында дини реформаторлык хәрәкәте башлана. Таҗетдин Ялчыгол (1768–1838), Г. Курсави (1776–1812), Г. Утыз Имәни (1754–1834), Г. Кандалый (1797–1860) хезмәтләре XIX йөзнең икенче яртысында татар мәгърифәтчелек әдәбияты тууга һәм үсүгә йогынты ясый.

Күренекле тел белгече, татар әдәби теленең барлыкка килү һәм яшәеш шартларын өйрәнгән галим В. Хаков татар милли әдәби теленең нормалашу һәм үсеш чорын XVIII гасыр ахырыннан – XX гасыр башына кадәр дип билгели[2]. Бу процесс телне демократияләштерү һәм әдәби телнең искергән нормаларыннан баш тарту, әдәби сөйләмгә якынаю юлы белән бара. Әлеге нигездә һәм татар теленең кайбер диалектлары катнашында хәзерге татар милли теле хасил була, ул К. Насыйри, Дәрдемәнд, Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Ибраһимов, Ш. Камал һ.б. әсәрләрендә камилләшә.

Тел берәмлекләрен куллануда үрнәк булырга тиеш дип санала торган жанр-стильләрдә, тел берәмлекләрен файдалануда билгеле бер графикага нигезләнеп, билгеле бер дәрәҗәдәге орфографик тәртип – язма норма формалаша, грамматик һәм лексик-семантик

---

[1] Татар дөньясы=Татарский мир / авт.-төз.: Г.Ф. Габдрахманова, Э.М. Галимова, Д.Ф. Заһидуллина, И.Л. Измайлов, А.Р. Салихова, А.Г. Ситдыйков, Л.М. Шкляева. Казан: Заман, 2019. Б. 135–136.

[2] Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. Б. 14.

форма һәм мәгънәләр ныгый. Махсус калыплашкан сөйләм типларын – стильләрнең ныклыгын барлыкка китерүе нәтиҗәсендә, язма норма, бер үк вакытта, әдәби телнең бөтенлеген хасил итә һәм әлеге телдә сөйләшүчеләрнең кайда яшәүләренә, һөнәрләренә, яшь аермаларына һ.б.га карамастан, халыкның (милләтнең) укый-яза белә торган белемле катлавы өчен аңлаешлы була. Әдәби тел нормаларына нигезләнеп сүзлекләр төзелә, грамматикалар, кулланмалар языла. Шулай итеп, фәнни әдәбиятта тотрыклы кулланыла торган сүзләр барлыкка килә; әлеге эшчәнлекне дәүләт саклый (мәсәлән, мәктәпләрдә укыту процессында); кирәк вакытта ул орфографиягә караган нормаларның кулланылышын кануни актлар белән билгеле һәм аларның сакланышын таләп итә. Әлеге нигездә шушы телдә сөйләшүчеләрнең җанлы сөйләменә хас төрле вариатив мөмкинлекләренең берсе, язма әдәбиятта кулланылуыннан чыгып, сайлап алына һәм әдәби тел (сөйләм) күренеше – норма буларак кабул ителә, төрле диалектларда сөйләшүче халыкны берләштерүче көчле факторга, уртак хәзинәгә әверелә[1].

1905 елның 2 сентябрендә Санкт-Петербургта беренче татар газетасы «Нур» басыла. Шушы вакыттан милли татар вакытлы матбугаты тарихы башлана, ул тиз арада татарларның иҗтимагыйсәяси тормышында күренекле урын яулый. Вакытлы матбугатта татар җәмгыятен үзгәртү-яңарту барышы чагыла. 1905–1917 елларда Россиядә татар телендә 62 газета һәм 30 дан артык журнал нәшер ителә. Китап басу өлкәсендә гаять зур активлык күзәтелә. XX гасыр башында шәхси басмаханәләр саны үсә, алар бер-бер артлы Казанда, Оренбургта, Уфада, Әстерханда, Стәрлетамакта, Санкт-Петербургта ачыла. Китап басу һәм китап сату ширкәтләре (Кәримовлар, «Сабах», «Мәгариф», «Милләт» һ.б.) барлыкка килә. 1910 елда Казанда 26 басмаханә эшли, аларда ел саен 1000 нән артык исемдәге китап нәшер ителә. 1901–1917 еллар арасында барлыгы 1191 оригиналь басма, 307 авторның 798 исемдәге китабы якынча 4 миллион данә тираж белән дөнья күрә. Фәнни басмалар арасында беренче урынны Р. Фәхреддин, Ә.-З. Вәлиди, Г. Баттал, Һ. Атласи, Г. Әхмәров, Х. Фәйзинең гомуми һәм милли тарихка

[1] Татар грамматикасы: өч томда. Т. I. / ред. колл.: М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, К.З. Зиннәтуллина. Мәскәү: Инсан; Казан: Фикер, 1998. Б. 42–43.

караган китаплары алып тора. Ислам тарихы һәм фәлсәфәсе буенча М. Бигиевнең, З. Камали, З. Кадыйри, Г. Буби һәм башкаларның күпсанлы хезмәтләре басыла.

Гасыр башы китап репертуарында тәрҗемә әдәбият зур урын били. Әгәр 1907 елга кадәр шәрык телләреннән тәрҗемәләр күпчелек булса, 1907–1911 елларда рус әдәбиятына өстенлек бирелә. Татар укучысы рус әдәбияты классикларының китапларын һәм чит ил авторларын үз телендә уку мөмкинлеге ала. XX гасыр башында яңа дөньяви татар әдәбияты туу, вакытлы матбугат, нәшрият эше киң җәелү, Шәрыктан – Гаребкә юнәлеш алу мәдәнияттә өр-яңа тенденцияләр хасил итә. XX гасыр башы татар әдәбиятының иң мөһим сыйфаты – милләт язмышын төп тема итеп күтәрү. Бу чорда мәгърифәтчелек әдәбияты үсеше дәвам итә: драматургиядә – Г. Исхакый, Г. Камал; поэзиядә – М. Гафури, Г. Тукай һ.б.; прозада – Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдов һ.б. Әсәрләрдә иске-яңа көрәше яңаның җиңүе белән тәгәлләнә.

Габдулла Тукай яңа милли шигърияткә нигез салучы, халык җырчысы булып таныла, үз шигъри мәктәбен булдыра. Аның иҗатыннан шәркый шигърият традицияләрен Европа һәм рус әдәбияты үрнәгендә, әмма милли үзенчәлекләрне саклаган хәлдә үзгәртү башлана.

1920–1930 елларда татар әдәбиятының төп массасын совет идеологик таләпләренә туры килгән әсәрләр тәшкил итә. Шул ук вакытта аның олы бер өлеше инкыйлабтан соң чит илләргә киткән татар әдипләре тарафыннан иҗат ителә. 30 нчы еллар сәяси репрессияләр сәясәте барышында татар әдәбияты коточкыч зур югалтулар кичерә: күп кенә танылган язучылар һәм әдәбият галимнәре юк ителә, әдәби иҗат эше исә соцреализм кысаларына куып кертелә, аны саклауны партия җитәкчеләре күзәтеп тора. Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы чор татар әдәбиятында ил мәнфәгатьләрен кайгырту беренче планга чыга, Ватан, туган җир төп кыйммәтләр буларак күтәрелә, патриотик пафос, гуманистик башлангыч көчәя. 1960 еллардан әдәбиятта миллилек калку билгеләнә башлый һәм ул буыннар арасындагы рухи бәйләнешләр өзелү, тел югалу, йола-гадәтләрнең, гасырлардан килгән әхлакый кыйммәтләрнең онытылуы, туган җир кадерен, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр матурлыгын күрмәү кебек татарлар өчен әһә-

миятле мәсьәләләрне гомумкешелек проблемалары итеп гомумиләштерә[1].

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбияты камилләшү чорын кичерә. Ул форма җәһәтеннән үзгәрешләр белән билгеләнә, әмма сүз сәнгате XX гасыр дәвамында табылган төп юлдан тайпылмый[2].

Татар теленең сүз байлыгын, нигездә, гомумтөрки лексика тәшкил итә. Гарәп һәм фарсы алынмалары борынгыдан килгән антропонимикада, рус алынмалары (моңа рус теле аша кергән интернационализмнар да керә) фәнни, техник, сәнәгать һәм төзелеш өлкәсенә караган сүзләрдә ешрак очрый.

## Стильләр тарихы

Иҗтимагый аралашуның теге яки бу өлкәсендә кулланыла торган тел чараларының тарихи барлыкка килгән системасын функциональ стиль дип атыйлар. Хәзерге татар тел белемендә традицион рәвештә аларның түбәндәге төрләрен аерып чыгаралар: матур әдәбият, иҗтимагый-публицистик, фәнни, рәсми-канцелярия һәм эпистоляр стильләр. Моннан тыш аерым галимнәр тарафыннан дини-дидактик стильнең булуы да таныла.

*Матур әдәбият стиле* башка стильләрдән үзенең нәфислеге, матурлыгы һәм югары яңгырашлылыгы белән аерылып тора. Анда күптөрле сөйләм үзенчәлекләре бергә кушыла. Барыннан да бигрәк, матур әдәбият стилендә сәнгатьчә сурәтләү алымнарына зур урын бирелә һәм язучының үзенә хас алымнары киң чагылыш таба. Тасвирлау чаралары кешенең хис-тойгыларына, эчке кичерешләренә тәэсир итә. Нәтиҗәдә чынбарлык күренешләренең сәнгатьчә сурәте тудырыла.

Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, матур әдәбият стиленең тарихы ерак гасырларга – VI–X гасырларга караган борынгы төрки рун язма истәлекләренә барып тоташа. Аларда чагылыш тапкан матур әдәбиятка хас тел-стиль үзенчәлекләре алга таба аерым шагыйрьләрнең әсәрләрендә дәвам иттерелә. Шундыйлардан XIII гасыр башында Кол Гали тарафыннан

---

[1] Татар дөньясы=Татарский мир / авт.-төз.: Г.Ф. Габдрахманова, Э.М. Галимова, Д.Ф. Заһидуллина, И.Л. Измайлов, А.Р. Салихова, А.Г. Ситдыйков, Л.М. Шкляева. Казан: «Заман» нәшрияты, 2019. Б. 137–149.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* Чал татар әдәбиятының 100 елы // Казан утлары. 2020. № 5. Б. 174, 178, 181.

тудырылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасын, Алтын Урда чорында иҗат ителгән «Хөсрәү вә Ширин», «Гөлестан бит-төрки», «Мәхәббәтнамә» әсәрләрен һ.б. атап үтәргә мөмкин.

Татар телендә матур әдәбият стиле күп гасырлар дәвамында, нигездә, поэтик әсәрләр нигезендә үстерелә. XIX гасыр ахырында татар әдәбиятында проза һәм драма жанрларында да әсәрләр иҗат ителә башлагач, ул, аларга хас үзенчәлекләр белән дә баетыла.

*Публицистик стильгә* хас үзенчәлекләр җәмгыять тормышында зур урын алып торган вакыйгаларга, әһәмиятле мәсьәләләргә багышлап язылган әсәрләрдә чагылыш таба. Аларда вакыйгалар һәм күренешләр, нигездә, ничек бар шулай тасвирлана. Авторның фантазиясе чикләнгән була. Ул укучының аңына тәэсир итәргә, аны теге яки бу фикернең логик яктан дөреслегенә ышандырырга тырыша һәм фәнни-теоретик фикерләү юлын сайлый.

Татар телендә публицистик стильнең беренче яралгылары Болгар, Алтын Урда дәүләтләрендә барлыкка килгән дип санала. Бу чорда халыкка мөрәҗәгать рәвешендә сөйләнгән чыгышлар, нотыклар, дипломатик документларның күбесе публицистик рухта булганнар. Әлеге традицияләр Казан ханлыгында да дәвам иткән. Моны Олуг Мөхәммәд ханның төрек солтаны Моратка язган рәсми хатында, Ибраһим хан, Сәхибгәрәй хан ярлыкларында ачык күрергә мөмкин. Шулай ук Шәрәфетдин ибне Хисаметдин әл-Болгаринең XVI гасырга караган «Рисаләи тәварихы Болгария» исемле әсәрендә тарихи-фәнни мәгълүмат публицистик сөйләм үрнәкләре белән үрелеп бара.

XVIII–XIX гасырларда публицистик стиль тәмам ныгып, үсеп җитә, ә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында, ул, аерым тармакларга бүленеп, жанр һәм эчтәлек ягыннан тагын да байый төшә. Бу чорда аның үсешенә җәмгыятьтә барган иҗтимагый, икътисади, мәдәни үзгәрешләр һәм татар телендә газеталар чыга башлау зур йогынты ясый.

Фәнни хезмәтләр өчен фактларны мөмкин кадәр төгәл һәм тулы аңлату, күренешләр арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен күрсәтү, тарихи үсеш закончалыкларын ачыклау һ.б. үзенчәлекләр хас. Алар билгеле бер логик эзлеклелектә язылалар, эчтәлекләренең өлешләре бер-берсе белән системалы бәйләнештә торалар, авторлар мөмкин булган дәрәҗәдә төгәллеккә, кыскалыкка һәм бермәгънәлелеккә омтылалар.

Татар телендә *фәнни стильнең* беренче яралгылары шулай ук ерак гасырларга барып тоташа. Тарихи чыганаклар күрсәткәнчә, Болгар дәүләтендә үк күп галимнәр яшәгәнлеге һәм аларның фәнни хезмәтләр язганлыгы мәгълүм. Мәсәлән, Якуб ибне Ногман әл-Болгари XII йөздә «Болгар тарихы» әсәрен иҗат итә, Әхмәт әл-Болгари риторика һәм фармацевтика, Хәмид әл-Идрис әл-Болгари философия буенча хезмәтләр яза. Моннан тыш мәдрәсәләр өчен дәреслекләр төзелә. Кызганычка каршы, аларның берсе дә бүгенгә кадәр сакланмаган. Безнең көннәргә килеп җиткән татар телендәге фәнни хезмәтләрнең иң борынгысы –1542 елда Казан ханлыгында язылган математика буенча «Мәҗмугыль-кавагыйд» («Кагыйдәләр җыентыгы») трактаты.

Татар телендә фәнни хезмәтләр язу алга таба да дәвам итә һәм XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында төрле тармакларны үз эченә алган фәнни әдәбият һәм аның стиле формалашып җитә. Бу чорда күп кенә дөньяви мәктәпләр ачыла һәм алар өчен төрле фәннәрдән заман таләпләренә җавап бирә торган дәреслекләр, методик әсбаплар һәм кулланмалар төзү көн үзәгенә куела.

*Рәсми-канцелярия* стиле телнең социаль әһәмияткә ия функциональ төрләренә керә, чөнки эшлекле сөйләм булдыру, аны үстерү һәм камилләштерү һәр җәмгыятьтә нәтиҗәле идарә итү һәм тәртип урнаштыру белән бәйле ихтыяҗларны тормышка ашыру чараларының берсе булып тора. Рәсми документлар һәм эш кәгазьләре беренче дәүләт оешу белән барлыкка килгәннәр һәм чордан чорга үзгәреп торганнар. Мәсәлән, Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханлыкларында дәүләт белән идарә итүдә хан ярлыклары зур роль уйнаган булса, Казан ханлыгы Россия дәүләте составына кертелгәннән соң, аларны патша указлары, манифестлары һәм грамоталары алыштыра. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яңа иҗтимагый һәм икътисади мөнәсәбәтләр урнашу сәбәпле, низамнамә (устав), шартнамә, кануннар һәм кагыйдәләр җыелмасы, хисап (отчет), циркуляр, беркетмә, гариза кебек эш кәгазьләре киң таралыш ала.

*Эпистоляр стильгә* аерым дәүләтләр, оешмалар һәм шәхесләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, кешеләрнең чынбарлык күренешләре, иҗтимагый һәм көнкүреш вакыйгалары турындагы фикерләрен, хис-тойгыларын, кичерешләрен чагылдырган хатлар, көндәлекләр, тәбрикнамәләр һәм шуңа охшаш башка язмалар керә. Татар телендә алар аерым бер стильне барлыкка китерәләр. Аның

тарихи үсешен күзәтү әлеге стильнең дәүләттә идарә эшләре белән мөнәсәбәтләрне тәртипкә салуда, төрле илләр арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруда зур роль уйнаганлыгын күрсәтеп тора. Мәсәлән, Алтын Урда һәм Казан ханнары тарафыннан төрле ил башлыкларына язылган рәсми хатлар безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарлар арасына яңа иҗтимагый һәм икътисади мөнәсәбәтләрнең үтеп керүе алга таба эпистоляр стильнең киң даирәгә җәелүенә зур йогынты ясаган. Нәтиҗәдә, кешеләр үзара хатлар язышып, ешрак аралаша башлаганнар.

## II БҮЛЕК
## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ДИАЛЕКТЛАРЫ

### Татар теленең диалектлары һәм сөйләшләре

Аерым милләтләрнең формалашуы аларның милли телләре барлыкка килү белән бергә бара. Шулай ук дәүләт барлыкка килү, башка халыклар белән аралашып яшәү рәсми мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен кирәкле уртак телгә ихтыяҗ тудыра. Әдәби тел нормага салынган, үзенең язмачылыгы булган, күп функцияле, стильләр ягыннан бай һәм диалектлардан өстен торган бердәм, гомумиләштереп килә торган телнең үзенчәлекле формасы буларак характерлана ала.

Татар әдәби теле аның урта һәм көнбатыш диалектлары нигезендә формалаша. Татар теленең төрле диалектларында сөйләшүчеләр уртак тарихи язмыш, рухи һәм матди мәдәният, телебездә күп гасырлар дәвамында барлыкка килгән билгеләр ярдәмендә, хәзерге вакытта аерым этник һәм тел билге-үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, бер халык, бер милләт булып яшәүләрен дәвам итәләр.

Төрле географик шартларда гомер итеп, кардәш яки кардәш булмаган халыклар белән борынгы чорлардан ук аралашып яшәү һәр диалектка, һәр сөйләшкә генә хас булган үзенчәлекләр туууга да сәбәп булган.

Диалектология фәне билгеле бер төбәкләрдә яшәүчеләрнең сөйләм телен өйрәнә. Татар авыллары, көнбатышта Рязань һәм Тамбов өлкәләреннән башлап, көнчыгышта Кемерово өлкәсенә һәм Красноярск краена, төньякта Вилюй елгасына, көньякта Әстерхан өлкәсенә хәтле сузылган гаять зур территориягә таралып утырганнар. Татар халкының иң зур күпчелеге Татарстан,

Башкортстан республикаларында гомер кичерә. Милләтебезнең яшәү үзәген тәшкил итүче бу республикалардан тыш татарлар Россия Федерациясенең күп кенә өлкәләрендә һәм милли республикаларында төпләнеп яшиләр.

Әлеге киңлекләрдә таралган татар теле өч диалектка – урта (казан татарлары), көнбатыш (мишәр) һәм көнчыгыш (себер татарлары) диалектларга бүленә. Татар шивәләрен төркемләү омтылышы беренче мәртәбә 1881 елда А.Г. Бессонов тарафыннан ясала. Бүгенге көндә яшәп килгән классификациянең нигезен Җ. Вәлиди, Л. Җәләй фикерләре тәшкил итә. Татар диалектларын, сөйләшләрен лингво-географик юл белән өйрәнү һәм «Татар теле диалектологик атласы»н төзү сөйләшләр һәм диалектларның гамәлдәге классификацияләренә мөһим өстәмәләр һәм аныклыклар кертү мөмкинлеге тудырды.

Татар теленең төп диалекты булып саналган *урта диалект* (казан татарлары диалекты) шактый зур территориядә, башлыча Татарстан һәм Башкортстан республикаларында, аларга якын булган төбәкләрдә – Чиләбе, Курган һәм Оренбург өлкәләрендә таралган күпсанлы сөйләшләрне үз эченә ала. Тарихи яктан алар болгар бабаларыбызның дәвамчылары булып торалар. Болгарлар исә үз чиратында төрле төрки (угыз, кыпчак) кабиләләрнең көчле Болгар дәүләте составында берләшүе нәтиҗәсендә формалашканнар.

Урта диалект сөйләшләре системасының катлаулы булуы байтак кына тарихи сәбәпләргә бәйле: Идел буе болгарларының җирле кыпчак кабиләләре тарафыннан ассимиляцияләнүе, күрше фин-угор, төрки, славян халыклары белән үзара тәэсир итешеп яшәүләре, бу халыкларның татарлар тарафыннан өлешчә ассимиляцияләнүе, бер өлеш татарларның дини изоляцияләнүе, территориаль яктан аерым этник төркемнәрнең төп массадан ерак урнашуы, соңгы вакытта көнбатыш диалект йогынтысының көчәюе һ.б.

Урта диалектка түбәндәге сөйләшләр керә: казан арты сөйләшләре төркеме (дөбьяз, мамадыш, лаеш, балтач – Татарстан), бәрәңге сөйләше (Марий Эл), тау ягы сөйләшләре төркеме (норлат – Татарстан, Чувашия; кама тамагы, тархан – Татарстан), керәшен сөйләшләре төркеме (казан арты керәшеннәре сөйләше – Татарстан; түбән кама керәшеннәре сөйләше – Татарстан, Башкортстан; нагайбәк сөйләше – Чиләбе өлкәсе), минзәлә (Татарстан, Башкортстан), бөре (Башкортстан), касыйм (Рязань өлкәсе), бастан

(Рязань өлкәсе), нократ (Удмуртия, Киров өлкәсе), пермь (Пермь крае), златоуст (Башкортстан), красноуфим (Урал федераль округы) эчкен (Курган өлкәсе), каргалы, богырыслан (Оренбург), камышлы (Самара өлкәсе), әстерхан (Әстерхан, Волгоград өлкәләре, Ставрополь крае), татар-каракалпаклар (Волгоград, Саратов өлкәләре), турбаслы, тепекәй, учалы, сафакүл, кормантау (Башкортстан)[1]. Бу сөйләшләр зур территорияләргә таралуга карамастан, аларның төп үзенчәлекләре уртак. Урта диалект сөйләшләренең зур күпчелеге әдәби телгә аеруча якын тора.

*Көнбатыш диалект* вәкилләренең бер өлеше, ягъни мишәрләр исә, болгарлар Урта Идел, Түбән Кама туфракларына күчеп килгәнче үк, әлеге җирләрдә Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорында акрынлап якын-тирә төбәкләргә үтеп кергән кыпчакларның варислары булып саналалар. Мишәр диалекты терминын беренче тапкыр Л. Җәләй үзенең «Татар телендә диалектлар» (1938) дип аталган фәнни хезмәтендә куллана. Система буларак, диалект Л. Мәхмүтова тарафыннан тасвирлана. Көнбатыш диалектның таралышын күрсәткән диалектологик карталарның системалы җыелмасы Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласында урын ала.

Көнбатыш диалект ике зур сөйләшләр төркеменә бүленә: чылаштыручы һәм цылаштыручы сөйләшләр. Бу сөйләшләр телнең барлык өлкәләрендә дә бер-берсенә бик якын.

*Цылаштыручылар* төркеменә – сергач (Түбән Новгород өлкәсе), чүпрәле (Татарстан һәм Чувашия), байкыбаш (Башкортстан) сөйләшләре; *чылаштыручылар* төркеменә исә темников, ләмбрә (Мордовия), кузнецк (Пенза өлкәсе), хвалын, мәләкәс, карсун (Ульяновск өлкәсе), тау ягы керәшеннәре, чистай керәшеннәре (Татарстан), стәрлетамак (Башкортстан), шарлык (Оренбург өлкәсе), куршин (Тамбов өлкәсе), волгоград (Әстерхан һәм Волгоград өлкәләре, Ставрополь крае) сөйләшләре керә. Кама аръягында формалашкан чистай сөйләше катнаш характерда, сөйләш вәкилләре сөйләмдә ике үзенчәлекне дә параллель кулланалар. Көнбатыш диалектның барлык сөйләшләренә дә хас гомуми үзенчәлекләр бар. Болардан тыш, әлеге төркемгә Әҗе (рус. Азеево; Рязань өлкәсе), Сыркыды (Сургодь; Мордовия), Күршә (Татарщино; Тамбов

[1] *Рамазанова Д.Б.* Урта диалект // Татар халык сөйләшләре: ике китапта. Беренче китап. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 21.

өлкәсе), Тархан (Тархань; Тамбов өлкәсе), Искил (Татарский Лундан; Мордовия) кебек аерым-аерым утырып калган авыллар керә. Бу авыллар Цна һәм Мокша елгалары бассейнында, Кадом өязендә, ягъни татар халкының мишәр этник төркеменнән булган вәкилләре элек яшәгән борынгы территориядә урнашканнар. Урта диалектның касыйм һәм бастан сөйләшләре белән бергә нугай теле йогынтысына дучар булганга күрә, аларда уртак күренешләр барлыкка килгән. Шуңа күрә күрсәтелгән авылларның сөйләше татар теленең төньяк-көнбатыш зонасын хасил итә[1].

*Чылаштыручы* төркем сөйләшләре борынгы чорда ук – темников һәм ләмбрә типларына бүленгән булган. Темников тибына темников сөйләше үзе (хәзерге Мордовиянең көнбатыш районнарында таралган), Мордовия һәм көньяк Пенза өлкәсенең Рузаевкага хәтле булган чиге буйлап утырган авыллар сөйләше керә; Пенза өлкәсенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге кайбер авыллар сөйләше дә шунда ук карый. Ләмбрә тибына исә ләмбрә (Мордовиянең көнчыгышында таралган) сөйләше керә.

Чылаштыручылар арасында катнаш сөйләшләр дә бар. Болар – кузнецк (Пенза өлкәсенең көньяк-көнчыгыш өлешендә) һәм хвалын (Ульяновск өлкәсенең көньягында) сөйләшләре. Аларның чиген билгеләве шактый кыен, чөнки акрынлап бер-берсенә күчү процессы бара. Алар икесе дә темников һәм ләмбрә сөйләшләре үзенчәлекләренә ия, әмма хвалын сөйләшендә ләмбрә һәм берникадәр сергач сөйләшләре белән уртаклык, кузнецк сөйләше белән чагыштырганда, ачыграк чагылган. Кузнецк сөйләшен исә көнбатыш һәм көнчыгыш урынчылыкка бүлеп карарга мөмкин. Беренчесе темников сөйләшенә хас үзенчәлекләрнең көчлерәк булуы белән көнчыгыш урынчылыктан аерыла төшә.

Яңа территорияләргә чагыштырмача соңрак (хәзерге Саратов өлкәсенең көньягына һәм Волгоград өлкәсенә) күчү нәтиҗәсендә барлыкка килгән авылларның (Алтавыл, Алтата һ.б.) сөйләшләре мөстәкыйль сөйләш яки урынчылык булып формалашып җитмәгәннәр. Ульяновск өлкәсенең төньяк-көнбатышындагы карсун төркеме белән дә шундыйрак хәл. Әмма ул борынгырак чорда

[1] *Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарского языка). М.: Наука, 1978. С. 261; Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. Б. 140–141.

(XVII гасыр), Карсун сызыгын төзегәч барлыкка килгән. Аларның сөйләше мөстәкыйль сөйләш булып формалашып җиткән, дип әйтү кыен, шулай да анда кайбер үзенчәлекләр күзәтелә, алар аерым утырган бер компактлы төркемне тәшкил итәләр. Шуларны исәпкә алып, бу төркем мөстәкыйль карсун сөйләше дип тәкъдим ителә. Башкортстанның көньяк-көнбатышындагы (стәрлетамак) һәм Оренбург (шарлык) өлкәсендәге көнбатыш диалект сөйләшләре дә чылаштыручы төркемгә карыйлар. Алар һәркайсы күрше сөйләшләр йогынтысын кичергәннәр.

Көнбатыш Себернең көньяктагы урманлы һәм урман-далалы өлешендә яшәгән кабиләләрнең күпчелеге төрки телдә сөйләшкәннәр. Аларның формалашуында угор, кет һәм самодий телләрендә сөйләшүче кавемнәр дә катнашкан. Тора-бара бу төркемнәр үзара катнашып һәм төркиләшеп беткәннәр.

Тарихчыларның әйтүләренә караганда, төркиләшү электэлектән Алтай, Енисей буйларында яшәгән төрки халыкларның тәэсире нәтиҗәсендә барган. Шушы төбәкнең күп кенә төрки телле кабиләләрен барлыкка китерүдә турыдан-туры катнашкан кыпчаклар көнбатыш себер татарларының да якын бабалары дип санала. Соңыннан көнбатыш себер татарларын формалаштыруда җирле төркиләр (кыпчак кабиләләре), Урта Азиядән килгән бохарлылар һәм Идел буе татарлары катнаша. Соңгыларының (ягъни казан татарлары) теле исә, җирле халык теленә көчле йогынты ясап, себер татарларына хас булган борынгы төрки сузык авазлар системасының Идел-Урал төрки телләре сузыкларына җайлашуына сәбәп булган.

Көнбатыш Себер татарлары диалекты *көнчыгыш диалект* дип йөртелә. Бу термин беренче мәртәбә Л. Җәләй тарафыннан кертелгән һәм, көнчыгыш диалект дигәндә, Төмән, Омск, Томск, Новосибирск өлкәләрендә яшәүче себер татарларының теле күздә тотылган. Себер татарлары гаять зур территориягә таралып яшиләр. Бу исә төрле төркемнәр арасында аерымлыкларның саклануына, аерым төбәкләр эчендә яңа күренешләр барлыкка килүгә китерә.

Территориаль-лингвистик принципка нигезләнеп, Д. Тумашева себер диалектларының түбәндәге бүленешен фәнгә кертеп җибәрде: тубыл-иртыш диалекты зур территорияне үз эченә ала, һәм биш сөйләшкә: төмән, тубыл (Тубыл, Вагай, Яркәү районнары),

саз ягы (Тубыл, Уват районнары), тәвриз (Омск өлкәсенең Тәвриз, Усть-Ишим, Знаменское районнары), тара (Омск өлкәсенең Тара, Большеречье, Колосовка районнары) сөйләшләренә бүленә. Том диалекты – яуштә-чат (Томск өлкәсенең Томск районы) һәм калмак (Кемерово өлкәсенең Юрга районы) сөйләшләренә. Бараба (Новосибирск өлкәсенең Бараба, Куйбышев, Кыштау, Венгерово, Уба, Чан районнары) диалекты бер компакт төркемнең сөйләшен тәшкил итә[1].

Соңгы елларда башкарылган фәнни тикшеренүләр татар әдәби теленең формалашуында һәр диалектның ролен төгәлрәк билгеләргә мөмкинлек бирде. Татар диалектологлары барлык татар диалектларының да (урта – казан татарлары, көнбатыш – мишәрләр, көнчыгыш – себер татарлары (тубыл-иртыш, бараба, том диалектлары)) нигезен борынгы кыпчак теле тәшкил итә, дигән нәтиҗәгә килделәр. Һәр диалектта, гомуми кыпчак фоны белән беррәттән, шул диалект өчен генә хас үзенчәлекләрне тәшкил итә торган башка болгар, фин-угор, кет, самодий кабиләләренә хас билгеләрнең дә булуы ачыкланды.

Һәр диалект үзен формалаштыруда катнашкан төрле этник төркемнәргә бәйле рәвештә, аңа гына хас булган үсеш юлын кичергән. Шулай итеп, татар теле диалектлары уртак системалы элементлар нигезендә милли телебезнең аерылгысыз бер өлешен тәшкил итәләр.

### Татар теле диалектларының үзенчәлекләре

Тоташ территориядә таралган диалектлар яки сөйләшләрнең чикләрен төгәл билгеләү мөмкин түгел. Мәсәлән, сөйләшкә хас үзенчәлекләрнең берсе теге яки бу торак пункттан соң инде күзәтелмәскә, ә икенчесе исә дәвам итәргә мөмкин. Шушы ук торак пунктта күрше сөйләшкә хас үзенчәлекнең дә табылуы ихтимал. Кыскасы, бер сөйләштән икенче сөйләшкә яки бер диалекттан икенче диалектка күчеш әкренләп бара. Күчеш зонасындагы авылларда янәшә таралган күрше сөйләшләрнең икесе өчен дә характерлы үзенчәлекләр кулланылырга мөмкин. Бу территорияне сөйләшара яки диалектара зона дип атау кабул ителгән, ә андагы

[1] Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. Б. 142.

сөйләш катнаш сөйләш була. Төп таралыш территориясенең чигендә урнашкан сөйләш чик сөйләше дип атала. Билгеле диалект вәкилләре төрле сәбәпләр аркасында төп яшәү җирлегеннән күченеп китсә, аларның яңа төбәктә формалашкан җирле сөйләме күчмә сөйләш дип атала[1].

Диалектлар һәм әдәби тел арасында үзенчәлекле аерма булу белән бергә, үзара тыгыз мөнәсәбәт тә яшәп килә. Җирле диалектлар, сөйләшләр хәзерге татар әдәби телен баетуда төп чыганак булып тора.

Диалектологиянең төп өйрәнү объектларыннан берсе – диалектизмнар. *Диалектизм* дип билгеле бер территориядә генә таралган, әдәби телдә кулланылмый торган тел үзенчәлекләрен атыйлар[2]. Тел белемендә диалектизмнарның берничә төрен аерып карыйлар.

*Фонетик диалектизмнар* – әдәби телдән аваз төзелешләре белән аерыла торган үзенчәлекләр. Аларга аваз тәңгәллекләре, аваз чиратлашуы, аваз өстәлү, аваз төшеп калу, саңгыраулашу һ.б. үзенчәлекләр керә. Бу төр үзенчәлекләр сузыклар өлкәсендә дә, тартыклар өлкәсендә дә күзәтелә. Сузыклар өлкәсендә түбәндәге үзенчәлекләрне күрсәтү зарур.

*Сузыклар тәңгәллеге*, ягъни диалекталь сүздә әдәби телдәге сузыкка икенче сузык тәңгәл килә. Мәсәлән: [и]~[ә]: *күчтинәч* (казан арты) – күчтәнәч; [а]~[ы]: *қапқан* (камышлы) – *капкын* һ.б. Бу күренеш хәл фигыль кушымчаларында да күзәтелә, ягъни *-ғанчы*/*-гәнче* кушымчасы *-ғынчы*/*-генче* булып әйтелә: *торғынчы* – торганчы, *җыйылғынчы* – җыелганчы, *күргенче* – күргәнче, *белгенче* – белгәнче. Басымлы һәм басымсыз [а] сузыгы, нечкә тартыклар белән янәшә килгәндә, татар теленең [ә] авазы белән тәңгәлләшә: (урта диалектта) *кәнсәләр* – канцелярия, *әрмийә* – армия, *әдерис* – адрес. Рус телендәге басым төшкән [о] сузыгы, татар теленең күп сөйләшләрендә (урта, мишәр диалектларында) [у] га күчә: *тучны* – точно, *ахуты* – охота, *гармун* – гармонь, *лимун* – лимон, *пучты* – почта. Киресенчә, рус телендәге басым төшкән [у] авазын татар телендәге [о] белән алмаштыру очраклары да бар. Мәсәлән: *сослон* – суслон, *сохари* – сухари. Бу авазларның бер-

---

[1] *Рамазанова Д.Б.* Мишәр диалекты // Татар халык сөйләшләре: ике китапта. Икенче китап. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 5.

[2] *Галиуллина Г.Р.* Хәзерге татар теле лексикологиясе. Казан: Казан. ун-ты нәшр., 2013. Б. 111.

берсенә күчеше артикуляцион һәм акустик яктан якын авазлар булулары белән аңлатыла.

*Сингармонизм* – сузыкларның, бер-берсенә йогынты ясап, үзара охшашланулары. Иренләшү гармониясе [о]–[ө] авазларының үзләреннән соңгы иҗекләрдә килгән [ы]–[е] авазларына тәэсир итеп, аларны иренләштерү күренешләрендә чагыла: *орчоқ* – орчык, *қош қоно* – кыш көне, *өмөт* – өмет.

*Аваз өстәлү һәм аваз төшеп калу күренешләре*. *Протеза* күренеше янәшә ике тартыкка яки татар теле өчен чит булган авазларга башланган сүзләрдә күзәтелә: (стәрлетамак сөйләше) *эрәт* – рәт, *эскәтер* – скатерть; билгеле бер төркем татар сүзләрендә: (стәрлетамак сөйләше) *өтөрмә* – төрмә, *эчеру* – черү (казан арты, керәшен сөйләшләре) *эрәқәт* – рәхәт, *эшәл* – шәл, *эшәм* – шәм һ.б. *Эпентеза* – янәшә тартыклар арасына сузык аваз өстәлү күренеше: (урта диалект) *күреше* – күрше, *җөрөмей* – йөрми, (көнбатыш диалект) *қарышы* – каршы, *митыр* – метр, *пылак* – флаг, (көнчыгыш диалект) *керәплә* – грабли һ.б.

*Дифтонглар* – ике сузык, яки сузык һәм сонантаның бер иҗектә килүе. Әдәби телдәге дифтонглардан тыш күпчелек сөйләшләрдә (мәсәлән, түбән кама һәм нагайбәк керәшеннәре сөйләшләрендә) *ыw/ew, ей* дифтонглары кулланыла, *ей* дифтонгы ачык иҗектә килгән тар *и* сузыгы урынына әйтелә: *ней* – ни, *бейем* – бием, *кечтей* – кечти (кечкенә), *үгей* – үги; стәрлетамак сөйләшендә даими *әй* дифтонгы әйтелә: *үгәй* – үги, *песәй* – песи, *тәпәй* – тәпи һ.б.

*Тартыклар тәңгәллеге*, ягъни диалекталь сүздә әдәби телдәге тартык авазга икенче тартык аваз тәңгәл килә. Киң таралган аваз тәңгәллекләренә тукталып үтик.

[п]~[ф]. Бу үзенчәлек татар сүзләрендә дә, төрле алынмаларда да закончалыклы тарихи күренеш булып тора. Урта диалектта: *тупырақ* – туфрак, *җапырақ* – йафрак (яфрак), *керпек* – керфек; көнбатыш диалектта: *сәпәр* – сәфәр, *көпөрлек* – көферлек, *пирештә* – фәрештә; көнчыгыш диалектта: *пурмы* – форма, *пылак* – флаг һ.б.

[ж]~[й]. Урта диалект сөйләшләренә *җылаштыру* характерлы, ягъни күпчелек очракта [ж] авазы [й] авазына тәңгәлләшә: *җәшел* – йәшел (яшел), *җул* – йул (юл), *җурған* – йурган (юрган), *җегет* – йегет (егет), *җаман* – йаман (яман) һ.б.

Көнбатыш диалектка сүз башында *йылаштыру* (бу күренеш әдәби телдә [җ] авазы белән башлана торган сүзләрдә дә күзәтелә): *йил* –җил, *йиләк* – җиләк, *йер* – җир һ.б.

[к], [к]~[х]. Бу тәңгәллек урта диалектның кайбер сөйләшләрендә (мәсәлән, керәшен татарлары сөйләшләрендә) очрый: *қатын* – хатын, *қалық* – халык, *қат* – хат, *мақырым* – мәхрүм, *ақық* – ахак, *җомақ* – оҗмах, *ақирәт* – ахирәт, *кәкөмәт* – хөкүмәт, *қәреп* – хәреф, *паскы* – пасха, *китырый* – хитрый.

Көнбатыш диалектта тирән тел арты [к], [ғ], [х] авазлары урынына тел арты [к], [г], [х] авазларын куллану хас: *кала* – кала, *ак* – ак, *сакла* – сакла, *карга*– карга, *барган* – барган, *хал'* – хәл, *хайлә* – хәйлә һ.б. [к]~[х] тәңгәллеге татар теленең барлык сөйләшләрендә дә төрле дәрәҗәдә таралган, керәшен сөйләшләрендә, кама тамагы, пермь сөйләшләрендә һәм көнчыгыш диалектта исә системалы рәвештә күзәтелә.

[к]~[т]. Бу үзенчәлек билгеле бер сүзләрдә генә очрый: *кенәген/ төнәген* – кичә, *keләү* (итү) – теләк итү, *келәнче* – теләнче, *келәнү* – теләнү, *укмурт* – удмурт (биредә [д] > [т] > [к]). Киресенчә дә булырга мөмкин: [т]~[к]: *читләwек* – чикләвек һ.б.

Фарингаль [һ] авазы, күпчелек татар сөйләшләрендәге кебек, бөтенләй әйтелми. Сүз башында бу аваз төшә: *әр* – һәр, *аман/ әмән* – һаман, *әрбер* – һәрбер, *аwа* – һава, *өнәр* – һөнәр, *ич* – һич, *әwәс* – һәвәс. Ике сузык арасында килгәндә [һ] тартыгы [ғ]/[г] белән алмашына яки бөтенләй төшеп кала: *җиғаз* – җиһаз, *бәғә* – бәһа, *җәғәннәм/ җәннәм* – җәһәннәм, *шәгәр/шәр* – шәһәр, *зәгәр* – зәһәр. Бу үзенчәлек – татар теле диалектларына хас булган уртак күренеш.

*Метатеза* (янәшә яки арадаш торган авазларның урыны алышу) күренеше түбәндәге мисалларда күзәтелә: (урта диалект) *җерегеменче* – егерменче, (көнбатыш диалект) *күгәлә* – күләгә, *күсәртү* – күрсәтү.

*Морфологик диалектизмнар* – әдәби телдән төрләндергеч яки ясагыч кушымчалар белән аерыла торган үзенчәлекләр. Морфологик диалектизмнар дигәндә, беренче чиратта, татар теленә хас морфологик категорияләрнең формалашуындагы яки аларның мәгънә төсмерләрендәге аерымлыклар күздә тотыла. Мәсәлән, инфинитивның урта диалектта *-мага/-мәгә, -ма/-мә* (*укымага китте, чийә ашама йарата*), себер диалектларындагы *-ғале/-гәле* (*укығале*

*китепте, цийә ашағале йарата*) формалары – диалекталь күренеш. Бер үк мәгънәне белдерә торган сүзләр сөйләшләрдә бер үк тамырдан төрле кушымчалар ярдәмендә ясалырга мөмкин. Мәсәлән, әдәби телдә йоткылык – *йотма;* әдәби телдә эремчек – *эрек* һ.б. I һәм II зат берлек сан тартым кушымчалары алган исемнәрнең төшем килеш формасы әдәби телдәгечә дә (*-ны*/*-не*), угыз формасында да (*-ы*/*-е*) ясала: *кулыңы* – кулыңны. Икеләтелгән тартым кушымчасын ялгау аеруча алмашлыкларда, *бер, каршы* сүзләрендә күзәтелә: *ансысы* – анысы, *босысы* – бусы, *берсесе* – берсе (казан арты, керәшен, тау ягы сөйләшләрендә). Ел фасылларын белдерә торган сүзләрдән -*лый*/*-ли(й)* кушымчалары ярдәмендә дәвамлы вакыт рәвешләре ясала: *қышлый* – кыш буе, *җәйли* – җәй буе (мамадыш сөйләше).

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльләрнең *-ған*/*-гән* кушымчалы формаларына зат кушымчалары урынына тартым кушымчалары ялгану мамадыш сөйләшенең үзенчәлекле билгеләреннән берсе булып тора: *килгәнем* – килгәнмен, *килгәнең* – килгәнсең, *килгәнебез* – килгәнбез, *килгәнегез* – килгәнсез; *алганым* – алганмын, *алганың* – алгансың, *алганыбыз* – алганбыз, *алганыгыз* – алгансыз.

Тамырлары [р] сонорына беткән хикәя фигыльләрнең киләчәк заман I зат берлек сан формасы тулы һәм кыска вариантларда кулланыла: *Барсысын да сөйләрем* (сөйләрмен), *гөлкәйем*. Хикәя фигыльләрнең *-ғәч*/*-қач* кушымчалы формаларына *-тын*/*-тен* аффикслары ялгану – Урал ареалындагы көнбатыш һәм урта диалект сөйләшләренә хас үзенчәлек. Мәсәлән: *килгәчтен, қайтқачтын*. Йөкләтү юнәлешенең ясалышында -*ғыр*/*-гер, -қыр*/*-кер* (урта диалектта), *-гыз*/*-гез* (көнбатыш диалект сөйләшләрендә) вариантлары күзәтелә.

Инфинитивның *-маға*/*-мәгә* формасы, нигездә, билгеле тәгъбирләрдә генә күзәтелә: *асрамаға бала бирү* – асраргa, *утырмаға бару* – кул эше белән еракта яшәгән туганыңа барып, берничә атна торып кайту (минзәлә сөйләше).

Лексик диалектизмнар дигәндә әдәби телдә булмаган, бары сөйләшләрдә генә очрый торган сүзләр күздә тотыла[1]. Мәсәлән, касыйм сөйләшендә *алсын* – килендәш; пермь сөйләшендә *иләсә* –

[1] *Рамазанова Д.Б.* Мишәр диалекты // Татар халык сөйләшләре: ике китапта. Икенче китап. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 5.

биялəй; нократ сөйлəшендə *башбата* – кабер ташы; мамадыш сөйлəшендə *хəмдəш* – туган-тумачалар, *сөлəн* – чылбыр; шарлык сөйлəшендə *ултар* – абзар алдындагы бүлеп чыгара торган урын; богырыслан сөйлəшендə *чөм* – утырта торган бəрəңге күзе; тау ягы сөйлəшендə *кон* – төс, *кəй* – ямьсез, начар; казан арты сөйлəшендə *кутаз* – кыңгырау; сергач сөйлəшендə *цəпе* – тастымал; бөре сөйлəшендə *чети* – тинтəк, ахмак; түбəн сөйлəшендə *агуын* – кыр тавыгы, *шəлтəп* – бишек; хвалын сөйлəшендə *буй* – күлмəкнең кысасы, өске өлеше; темников сөйлəшендə *сакма йага* – изү; стəрлетамак сөйлəшендə *кийенчəк* – киемнəн тыш һəртөрле бизəнү əйберлəре, *муентəңкə(се), пөтөн тəңкə, мунса* – тəңкəлəр тезеп эшлəнгəн, муенга киелə торган бизəнү əйбере; богырыслан, стəрлетамак сөйлəшлəрендə *питырас* – калган камырдан пешерелгəн кечкенə икмəк; темников, лəмбрə, кузнецк сөйлəшлəрендə *мешке* – эремчек, *җəймə* – яхшы он һəм күкəйдəн генə əзерлəнгəн төче камырны юка гына итеп җəеп, майда пешерелгəн камыр ашы; стəрлетамак сөйлəшендə *тəкə* – кечкенə сумса, *күптермə* – борчак онынннан пешерелгəн калынрак коймак; минзəлə, нократ сөйлəшлəрендə *ак//сийыр агы* – сөт һəм аның продуктлары; стəрлетамак сөйлəшендə *кормош* – шөпшə, *ак таракан* – кыргаяк һ.б.; стəрлетамак, минзəлə сөйлəшлəрендə *кырмаюык, кырмалау* – тигəнəк; бөре сөйлəшендə *кəберкə//кəбəркə* – мич белəн стена арасындагы урын; байкыбаш сөйлəшендə *уша* – мич буенда яки ишек ягы стена буенда комган, киез итек кебек əйберлəр кую өчен җайланган тар такта, *купы* – аш савыты, *кəлземə//кəлҗемə* – черегəн бəрəңге күмəче һ.б[1].

Шулай итеп, əдəби тел сөйлəшлəргə даими рəвештə йогынты ясый, җирле сөйлəмгə тиз үтеп керə. Күп кенə диалектизмнар, бигрəк тə лексик берəмлеклəр, əдəби тел сүзлəре белəн алыштырылып, кулланыштан төшеп, онытыла, бетə баралар. Шул ук вакытта фонетик, грамматик аерымлыклар бигрəк тə тотрыклы булулары белəн аерылып торалар, алар аерым җирлектə яшəүчелəрнең сөйлəшлəрендə яшəп килəлəр, буыннан буынга күчеп, аерым бер сөйлəшнең, диалектның үзенчəлеген билгелилəр.

---

[1] Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зəкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. Б. 144–149.

## III БҮЛЕК
## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ

### Татар теленең нормалары

Татар язуы аваз-хәреф язуыннан гыйбарәт. Телдәге авазлар анда шартлы график билгеләр – хәрефләр белән билгеләнә. Хәзерге татар алфавиты 39 хәрефтән тора. Басма һәм кулъязма хәрефләрнең һәркайсының баш һәм юл хәрефе формалары бар: Аа Әә Бб Вв Гг Дд Ее Ёё Жж Җҗ Зз Ии Йй Кк Лл Мм Нн ң Оо Өө Пп Рр Сс Тт Уу Үү Фф Хх Һһ Цц Чч Шш Щщ ъ Ыы ь Ээ Юю Яя.

Хәзерге татар әдәби телендә 12 сузык аваз бар. Шуларның тугызы – [а], [ә], [у], [ү], [о], [ө], [ы], [е], [и] татар теленең үз сүзләрендә, өч аваз –[ы̄], [о̄], [е̄] рус теленнән кергән алынма сүзләрдә кулланыла.

Тартык авазлар – егерме алты. Алынма сүзләрдә һәм диалектларда тагын биш тартык очрый – [ц], [ᵗч], [щ], [в], [х].

Тел белемендә сөйләм авазларын язуда күрсәтү өчен орфографик язудан беркадәр аерыла торган махсус язу системасы кулланыла. Бу язу фонетик транскрипция дип атала. Анда кириллица яки латиница хәрефләре файдаланыла, кайбер үзенчәлекле авазларны чагылдыру максатыннан махсус билгеләр һәм тамгалар өстәлә.

Артикуляцион яктан, әйтелешләре буенча, сузыклар түбәндәгечә төркемләнә: телнең горизонталь хәрәкәтенә мөнәсәбәтле рәвештә татар сузыклары *алгы рәт (нечкә)* [ә] [э] [ө] [ү] [и] [э̄] һәм *арткы рәт (калын)* [а] [ы] [о] [у] [ы̄] [о̄] сузыкларына; телнең вертикаль хәрәкәтенә мөнәсәбәтле рәвештә *югары* [у] [ү] [и] [ы̄], *урта* [о] [ө] [ы] [э] [о̄] [э̄], *түбән* [а] [ә] күтәрелешле сузыкларга;

авазларны әйткән вакытта иреннәрнең катнашу-катнашмауларына карап, *иренләшкән* [у] [ү] [о] [ө] [о̄] һәм *иренләшмәгән* [а] [ә] [и] [э] [ы] [ы̄] [э̄] сузыкларга бүленәләр. Акустик яктан, яңгырашлары буенча, микъдари озынлыкка карап, сузыклар *чагыштырмача кыска* [о] [ө] [ы] [э] һәм *чагыштырмача озын* [а] [ә] [у] [ү] [и] [ы̄] [э̄] [о̄] авазларга бүленәләр.

Сингармонизм, яки сузыклар гармониясе – барлык төрки телләр өчен дә диярлек (чуваш һәм үзбәк телләреннән башка) характерлы билге. Сингармонизмның ике төре бар – рәт гармониясе һәм ирен гармониясе.

Рәт гармониясе – сузыкларның рәт буенча охшашланулары, җайлашулары: әгәр сүзнең беренче иҗегендә арткы рәт сузыгы булса, калган иҗекләрдә дә арткы рәт сузыклары килә һәм киресенчә. Мәсәлән, *башкаручыларыбыз, үткәрмәделәр* һ.б. Бу күренешне тулы, өлешчә, арадаш ассимиляция дип карап була. Алынма сүзләрдә (*имтихан, галим, телефон, кофе*), кушма сүзләрдә (*өчаяк, төнбоек, Илдус, Гөлнар*), кайбер зат алмашлыкларында (*миңа, сиңа*), кайбер кушымчалар аркасында (көлсу, улмыни) рәт гармониясе сакланмый.

Татар телендә ирен гармониясенең эчтәлеге түбәндәгеләрдән гыйбарәт: әгәр сүзнең беренче иҗегендә иренләшкән [о], [ө] сузыклары булса, шуннан соңгы иҗекләрдә килә торган [ы], [е] сузыклары иренләшеп, [о], [ө] булып әйтелә: *кол-ы* > [қоло́], *көтеп* > [көтө́п]. Монысын туры, тулы арадаш ассимиляция дип карарга мөмкин. Шунысын искәртергә кирәк: иренләштерү тәэсире икенче иҗектә генә көчле була, калган иҗекләрдә әлеге күренеш шактый зәгыйфьләнә.

Иренләшкән [у], [ү] сузыкларының мондый ассимилятив үзлекләре булмый. Этимологик яктан бер тамырга кайтып кала торган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр *сингармоник параллельләр* дип аталалар: *аз – әз, акрын – әкрен, бавыр – бәгырь, ана – әни, багланыш – бәйләнеш, чыкылдау – чекелдәү* һ.б. Алынма сүзләр татар теленә кергәндә еш кына сингармонизмга буйсындырып кабул ителгәннәр: *скатерть* > *эскәтер, бревно* > *бүрәнә, мәкъсат* > *максат, дәстрүмал* > *тастымал* һ.б. Сингармонизмның табигатен еш кына төрле сөйләм органнарының инертлыгы, «ялкаулыгы» белән аңлаталар. Тарихи яктан караганда, алгы рәт сузыкларының активлашу тенденциясе турында да фикерләр бар. Моны телдәге

экономия принцибы белән, алгы рәт сузыкларын әйтүнең җайлырак булуы белән аңлаталар[1].

Тартык авазларга артикуляцион классификация ясаганда, аларның ясалу урынына, ысулына һәм тавыш ярыларының эшчәнлегенә игътибар итәләр. Тартыкларны ясалу урыны буенча төркемләгәндә, үпкәдән килгән һава агымына сөйләм аппаратының кайсы урынында тоткарлык ясалу игътибарга алына. Бу яктан тартык авазлар түбәндәге төркемнәргә бүленәләр: *ирен-ирен тартыкларын* ([б], [п], [м], [w]) әйткәндә, аскы һәм өске ireннәр бер-берсенә таба хәрәкәт итәләр; *ирен-теш тартыкларын* ([ф], [в]) әйткәндә, аскы ирен өске кискеч тешләргә таба хәрәкәт итә; *тел алды тартыкларын* ([т], [д], [н], [с], [з], [ч], [ж], [ш], [щ], [л], [р], [ц], [җ]) әйткәндә, телнең алгы өлеше өске тешләргә һәм теш казналарына таба хәрәкәт итә; *тел уртасы тартыгын* [й] әйткәндә, телнең уртасы каты аңкауга таба күтәрелә; *тел арты тартыклары* ([к], [г], [х’] > [х̡’] [ң’]) ясалганда, телнең арткы өлеше йомшак аңкауга таба күтәрелә; *кече тел тартыклары,* яки *увуляр тартыклар* ([қ], [ғ], [х] > [х̡], [ң] ясалганда, кече тел белән телнең арткы өлеше бер-берсенә якынаялар; *йоткылык тартыгы,* яки *фарингаль тартык* – [һ] йоткылык стеналарының тараюы һәм һаваны шулар аша көчле итеп өреп чыгару юлы белән ясала; *бугаз тартыгы,* яки *ларингаль тартык* – һәмзә [’] бугазда тавыш ярыларының йомылуы һәм кисәк кенә ачылып китүе нәтиҗәсендә ясала.

Һава агымына тоткарлыкның ничек ясалуына карап, тартыклар йомык, өрелмәле, ярымйомык һәм калтыраулы булалар. *Өрелмәле (фрикатив) тартыклар* ясалганда, сөйләм аппаратының берәр урынында тарайган урын, ярык була; һава агымы шул ярыкның стеналарына ышкылып үткәндә, турбулентлы һава өермәсе нәтиҗәсендә аваз барлыкка килә. Өрелмәле тартыклар бер фокуслы ([ф], [в], [с], [з], [х], [г], [w], [һ], [ж], [’], [й]) һәм ике фокуслы ([ш], [щ], [җ]) булалар. Бер фокуслыларны әйткәндә, һава агымы бер генә тарайган урын (фокус) аша үтә, ә ике фокуслылар берьюлы ике урыннан һава өрелеп чыгу нәтиҗәсендә ясалалар. *Йомык тартыклар* ясалганда, сөйләм органнарының берәрсе тулысынча йомыла һәм

[1] Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. Б. 31–32.

үпкәдән килгән һава агымы тәэсирендә кисәк кенә ачылып китә. Әгәр йомылу тулысынча ачылып китсә, саф йомык тартыклар ([п], [б], [т], [д], [к], [к], [г], [’]) ясала. Әгәр йомылудан соң өрелү этабы башланып, сөйләм органнары шуннан соң гына ачылып бетсәләр, аффрикат тартыклар ([ц], [тч]) барлыкка килә. *Ярымйомык тартыклар* ясалганда, сөйләм аппаратының бер урынында йомылу була, шул ук вакытта икенче бер урында һава үтү өчен урын кала. Ярымйомык тартыкларны әйткәндә, һава борын аша үтсә, аларны борын тартыклары ([м], [н], [ң]) дип атыйлар; әгәр телнең очы өске тешләргә тиеп, һава агымы телнең ян-ягыннан үтсә, ян-як тартыклары ([л]) дип атыйлар. *Калтыраулы тартыкларны* әйткәндә, телнең очы югарыга күтәрелә һәм һава агымы тәэсирендә калтыранып тора, шулай итеп [р] тартыгы ясала.

Тавыш ярыларының катнашу-катнашмавына карап, тартыклар яңгырау һәм саңгырау булалар. *Саңгырау тартыкларны* [с], [х],[һ], [п], [ч], [т], [к], [ш], [к], [ц], [ч], [щ], [’] әйткәндә, тавыш ярылары тибрәнмиләр, тавыш катнашмый; ә *яңгырау тартыкларны* ([б], [д], [в], [w], [з], [ж], [җ], [г], [ғ], [р], [н], [ң], [й], [л]) әйткәндә, тавыш ярылары тирбәлеп тавыш чыгаралар.

Гомум кабул ителгән, бердәм нормаларга салынган һәм һәркемгә мәҗбүри саналган практик язу системасы, ягъни әдәби телнең фәнни нигезләнгән, дәүләт тарафыннан законлаштырылган язу кагыйдәләре җыелмасы *орфография* (грекча *orthos* «дөрес» һәм *grapho* «язам») дип атала.

Орфография төзүдә берничә принцип бар: фонетик, морфологик, тарихи-традицион һәм график принциплар. Бу принциплар, телнең фонетик-морфологик үзенчәлекләреннән чыгып, төрле телдә төрле дәрәҗәдә кулланыла.

Сүз төрләнү һәм үзгәрү белән авазлары артык күп үзгәрүләргә, чиратлашуларга дучар булмаган телләрнең язуы өчен фонетик принцип, һичшиксез, төп нигез итеп алына. Ул, нигездә, ишетелгәнчә язуга таяна. Морфологик принцип – сүздәге морфемаларны һәрвакыт бер төрле язудан һәм сүз үзгәргәндә туган аваз үзгәрүне күрсәтеп тормаудан гыйбарәт: *унбиш, әнкәй, иртәнге, болын, сөлге.* Тарихи-традицион принцип – шул телнең элеккеге язу үзенчәлекләрен, традицияләрен саклап язу: *сурәт.* График принцип – рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләрне рус телендәгечә язу: *комитет, автомат, компьютер.*

Әдәби телдәгечә дөрес әйтелеш кагыйдәләре *орфоэпия* (*orthos* «дөрес» һәм *epos* «сөйләү») дип йөртелә.

Орфоэпия халык арасында әдәби әйтелеш нормаларын урнаштыруны максат итеп куя. Татар теленең әдәби әйтелеше урта диалектка нигезләнгән. Казан шәһәре күп гасырлар буе татар халкының мәдәни, сәяси үзәге булып торганлыктан, Казан татарларының сөйләше башкалар өчен дә үрнәк булган. Язма әдәбиятның бу тирәгә күбрәк тупланувы да нык тәэсир иткән.

Әдәби әйтелеш үзе төп ике төргә бүленә: язма-китаби стиль һәм җанлы сөйләм стиленә.

*Язма-китаби стиль* сөйләмнең бик анык булуы таләп ителгән очракларда, мәсәлән, радиотапшыруларда (диктор сөйләмендә), доклад яки чыгыш ясаганда, лекция укыганда яки дәрес биргәндә, ягъни сөйләүче язма тел стильләренең берсе белән эш иткәндә кулланыла. *Җанлы сөйләм стиле,* үзеннән-үзе аңлашылганча, кешеләрнең үзара сөйләшеп аралашуларында – диалогларда кулланыла. Язма-китаби стильдә сүзләрнең барлык иҗекләре дә диярлек ачык әйтелә. Җанлы сөйләм стилендә, киресенчә, кайбер иҗекләрнең кыскаруы яки бөтенләй төшеп калуы күзәтелә. Авазларның (тартыкларның да, сузыкларның да) әйтелеше, аларның комбинатор үзгәрешләре исә һәр ике стильдә дә, нигездә, бер үк.

Әдәби әйтелешне бозып сөйләүнең сәбәбе берничә булырга мөмкин. Мәсәлән, язылыш белән әйтелеш арасында зур аерма булу (сүз бертөрле языла, икенче төрле әйтелә). Мондый хәл орфографик кагыйдәләрнең, графиканың төгәл булмавыннан килә: гомер [ғөмөр], *канәгать* [қәнәғәт], *кыйммәт* [қиммәт] һ.б. Әдәби телгә диалект һәм сөйләшләрнең дә йогынтысы зур, нәтиҗәдә әдәби әйтелеш нормалары үзгәрергә мөмкин: мәсәлән, *җырак* (ерак), *бәк матур* (бик матур), *әчкеч* (ачкыч), *назан* (надан), *телке* (төлке) һ.б. Әдәби әйтелешкә рус теле дә кире йогынты ясый ала.

Татар телендә сүзләрне төркемләү лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик принципларга нигезләнә. Аларны сүз төркемнәренең классификация билгеләре дип тә атыйлар.

*Лексик-семантик принципка* таянып сүзләрне төркемләгәндә, аларның гомуми лексик мәгънәләре исәпкә алына. Гомумлексик мәгънә дип сүзләрнең конкрет лексик мәгънәләренә бәйсез, билгеле бер үзенчәлек буенча гомумиләштерелгән мәгънәләрен атыйлар. Телдәге аерым төркем сүзләр (мәсәлән, һәртөрле предмет,

күренеш, вакыйгалар) киң мәгънәдә предметлык төшенчәсен, ә кайберләре исә эш-хәл, предметлык билгесе һ.б. кебек гомумиләштерелгән мәгънәләрне белдерәләр. Бу үзенчәлек – сүз төркемнәренең семантик ягы дип атала.

*Морфологик принцип* буенча сүзләрне төркемләгәндә, аларның төрләнү мөмкинлеге, ягъни аларга хас грамматик категорияләр исәпкә алына. Телдә сүз төркемнәренең төрләнү мөмкинлеге төрлечә, ягъни һәр сүз төркеменең үзенә хас грамматик категорияләре бар. Әйтик, исемнәр – килеш, тартым, сан белән фигыльләр заман, зат-сан, юнәлеш белән төрләнәләр, ә кайбер сүз төркемнәре үзләренең төрләнмәве белән башка сүз төркемнәреннән аерылып тора (мәсәлән, рәвеш). Сүз төркемнәренә хас бу үзенчәлек – аларның морфологик яки грамматик ягы дип атала.

*Синтаксик принцип* булганда, сүзләрнең җөмләдәге типик функцияләре һәм сөйләм эчендә үзара бәйләнешкә керү мөмкинлекләре исәпкә алына. Исем, мәсәлән, җөмләдә күбрәк ия һәм тәмамлык булып килә; сыйфат – аергыч, фигыль хәбәр функциясен башкара һ.б. Әмма татар телендә бер үк сүз төркеменә кергән сүз теләсә нинди җөмлә кисәге булып та килергә мөмкин. Шуңа күрә бу очракта теге яки бу сүз төркеменең иң еш кулланыла торган, ягъни типик функциясе нигез итеп алына.

Татар теленең сүзлек составы гасырлар дәвамында формалашып, үсеш-үзгәреш кичергән хәлдә, бербөтен система буларак, бүгенгәчә килеп җиткән. Тел һәм сөйләм һәрвакыт үзгәреп тора. Иң беренче чиратта, телне, әлбәттә, халык үзгәртә, үзенең тормышы, көнкүреше үзгәрүе нәтиҗәсендә телгә дә үзгәрешләр кертергә мәҗбүр була.

Телдәге сүзлек составының төп һәм периферия катламнары аерып чыгарыла. *Төп катлам* – лексик фондның үзгәрешләргә бирелми яисә аз бирелә торган, тел үсешенең иң борынгы чорларына караган өлеше. Гадәттә, мондый сүзләрнең телдә кайчан барлыкка килүен дә билгеләп булмый. Төп сүзлек составы кардәш телләрнең барысында да кулланыла, мәгънәви һәм фонетик яктан да тотрыклылык белән сыйфатлана. Аңа бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән һәм тормыш өчен иң әһәмиятле төшенчәләрне белдерә торган тамыр сүзләр һәм ясалма нигезләр, генетик чыгышын билгеләп булмый торган, телнең үз сүзләренә әйләнгән алынмалар керә. *Периферия* (читтәге) *катлам* исә лексик фондның аерым бер

чорда телгә килеп кергән яисә телнең үз мөмкинлекләре нигезендә ясалган, үзгәрешләргә күбрәк бирелә торган өлешен тәшкил итә[1].

Төрки халыкларның формалашуы барышында борынгы чорда ук көнчыгыш халыклары белән булган багланышлар зур роль уйнаган, телдәге алынмаларның иң борынгылары да шулар белән бәйле. Төрки телгә кытай, һинд, иран, монгол һәм башка телләрдән күп кенә сүзләр үтеп кергән. Мәсәлән, шундыйлардан һинд, кытай сүзләрен билгеләп китәргә кирәк: *тәңре, җиз, сан, энҗе, хан, чәй, юан, шан, чын, чиру, алма, дию* һ.б.; монгол теле белән уртак сүзләр: *чаган, нукта, дилбегә* һ.б. Әлеге бәйләнешләр һәм шуларга мөнәсәбәтле рәвештә үтеп кергән алынмалар төрки телләр әле аерылмаган чорда ук кабул ителгәннәр.

Татар телендә фин-угор телләреннән кергән алынмалар да шактый: *пилмән, бүкән, миләш, морж, поши, килька, салака, пихта, камбала* һ.б.

Татар телендә саны һәм активлыгы белән аерылып торган гарәп һәм фарсы сүзләре дә күп. Бу алынмалар Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителгәннән соң, сәүдә, дини, сәяси, мәдәни һәм әдәби бәйләнешләр аша тагын да күбрәк үтеп кергәннәр. Баштан ук һәм бүгенге көндә лингвистик яктан төрле үзгәрешләргә дучар булганнар. Аларны үзләштерү – гасырлар дәвамында барган процесс.

Татар һәм рус халыкларының бабалары – төркиләр һәм славяннарның борын-борыннан күршеләр булып аралашып яшәүләре төрки халыкларның Көнчыгыш Европага килү вакыты белән бәйле.

Татар теленә рус алынмалары керү вакытын шартлы рәвештә берничә дәвергә бүлеп карарга мөмкин: I дәвер (IX–XVI йөзләр); II дәвер (Казан ханлыгы яулап алынудан XVIII гасыр азагына кадәр); III дәвер (XVIII гасыр – XIX гасырның икенче яртысы); IV дәвер (XIX гасыр азагы – Октябрь инкыйлабына кадәр); V дәвер (Октябрь инкыйлабыннан соң – XX гасырның икенче яртысы), VI дәвер (XX гасыр азагы – бүгенге көнгә кадәр)[2].

Кулланылыш сферасы ягыннан татар теленең сүзлек составы берничә төркемгә аерыла. Гомумхалык теле сүзләре иң зур урынны

[1] Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. Б. 15–16 .

[2] *Сафиуллина* Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология: югары уку йортлары студентлары өчен. Казан: Хәтер, 1999. Б. 67.

алып тора. Болар – барлык кешеләр өчен дә аңлаешлы, иң кирәкле сүзләр. Бу төр лексика милли әдәби телнең үзәге санала, гомумкулланылыш лексикасы барлык стильләрдә һәм телнең төрле катламнарында иркен кулланыла.

Икенче бер төркемне билгеле бер иҗтимагый катлам, коллектив, территория белән чикләнгән кешеләр куллана торган сүзләр тәшкил итә. Мондый сүзләргә диалекталь лексика, һөнәрчелек лексикасы, арго һәм жаргон сүзләр керә.

Телнең билгеле бер төбәктә генә таралган төрен диалект, җирле сөйләш дип атыйлар. Шул төбәккә генә хас, гомумхалык теленә кермәгән сүзләрне диалекталь лексикага кертеп карыйлар. Диалекталь сүзләр территориаль яктан чикләнгән булалар. Татар теле өч диалектка бүленә: урта диалект, көнбатыш диалект, көнчыгыш диалект.

*Һөнәрчелек лексикасы* – билгеле бер һөнәр кешеләре генә куллана торган сүзләр. Алар махсус төшенчәләрне, эш коралларын, хезмәт процессын белдерәләр. Диалекталь сүзләрдән аермалы буларак, һөнәрчелек лексикасы иҗтимагый яктан чикләнгән була. Төрле һөнәр ияләренең үзләренә генә хас сүзләре була: табиблар, укытучылар, балыкчылар, хәрбиләр һ.б.

*Жаргон* – уртак кызыксынулар белән яшәүче кешеләр (билгеле бер һөнәр ияләре, уен белән мавыгучылар, укучылар, студентлар, урам яшьләре һ.б.) арасында гына кулланыла торган үзенчәлекле сүзләр.

Жаргон сүзләрнең бер өлешен *арго* сүзләр диләр. Ул – сүзнең мәгънәсен башкалар аңламаслык итеп сөйләшү алымы. Элегрәк арго сүзләр теге яки бу һөнәрнең серләренә башкалар төшенмәсен өчен кулланылган. Ә хәзер балалар яисә яшүсмерләр телендәге һәр иҗек алдыннан берәр хәреф кушып сөйләшүне, караклар, җинаятьчеләр телендәге сүзләрне, шактый активлашып киткән парольләрне арго лексикага кертәләр.

Кулланылыш дәрәҗәсе буенча лексиканың ике төп катламы аерып карала: актив сүзләр (актив лексик фонд) һәм пассив сүзләр (пассив лексик фонд).

*Актив* лексикага мәгънәләре бүгенге көндә татарча сөйләшүчеләргә таныш булган, сөйләмдә актив кулланыла торган сүзләр керә. Кайчан барлыкка килүләренә бәйсез рәвештә, аларда искергәнлек яисә яңалык төсмере сизелми. Актив лексика сүзлек составының нигезен тәшкил итә.

Бүгенге көндә аралашуда сирәк кулланыла торган сүзләр *пассив* лексика дип атала. Алар тулысынча кулланылыштан чыккан, яисә чыгып бара, я булмаса, әле яңа гына барлыкка килү сәбәпле, киң кулланылышка кереп өлгермәгән. Пассив лексика, нигездә, тарихи темага караган әсәрләр, фәнни әдәбият һәм өлешчә көндәлек матбугат телендә генә чагылыш таба. Пассив сүзлек фонды ике зур төркемгә аерыла: искергән һәм яңа сүзләргә.

*Искергән сүзләр* дип инде көндәлек тормышта бөтенләй кулланылмый торган яисә төрле лингвистик һәм экстралингвистик сәбәпләр аркасында актив кулланылыштан чыккан сүзләргә әйтәләр. Кулланышта булмасалар да, искергән сүзләрнең мәгънәсе, гадәттә, аңлаешлы була: *алпавыт, аршын, чабата, кабилә, ясак* һ.б. Кайбер искергән сүзләрнең мәгънәсен исә төрле белешмә әсбаплар, сүзлекләр аша гына ачыклап була: *мәгыйшәт* (тормыш), *буга* (үгез), *барымта* (мал тартып алу өчен яу) һ.б.

*Тарихи сүзләр* – кулланылыштан төшеп калган предмет, күренеш, төшенчәләрнең атамалары. Тематик яктан алар төрле тарихи сословие, вазифа, һөнәр исемнәренә (*алпавыт, барчук, ишан, тархан, ямчы* һ.б.), хәрби өлкәгә (*айбалта, йөзбашы, никрут* һ.б.), элек кулланылышта булган үлчәү берәмлекләренә (*аршын, әчмуха, мыскал, фәрсәх* һ.б.), элекке административ-ыруг һ.б., үткәндәге тормыш-көнкүрешне чагылдырган сүзләр һәм хуҗалык кирәк-яраклары атамаларына (*әвен, гөбе, имана, киле, ясак* һ.б.) карый.

*Архаизмнар* – нинди дә булса предмет, күренеш, төшенчәнең искергән атамалары. Тарихи сүзләрдән аермалы буларак, актив лексикада архаизмнарның синонимнары була. Башкача әйткәндә, архаизмнар – төрле сәбәпләр аркасында башкалары тарафыннан телдән кысрыклап чыгарылган сүзләр. Лексик архаизмнар – барлык мәгънәләрендә дә кулланыштан чыккан, искергән сүзләр: *алтатар* – наган, револьвер; *ат* – исем, *сала* – авыл һ.б. Семантик архаизмнар – аерым мәгънәләре генә искергән сүзләр: *әрдәнә* – запас; *ил* – кабилә берлеге, халык; *йорт* – ил, нәсел-нәсәп, династия; *кап* – тире, мех; *капот* – киң итеп тегелгән күлмәк; *кара* – укымаган, надан; *кот* – бәхет; *көн* – кояш; *тары* – иген җире; *тун* – гомумән кием; *төрә* – закон; ялчы – хезмәтче. Фонетик архаизмнар – аваз составы үзгәргән сүзләр: *баг – бау, богдай – бодай, еглау – елау, ягмур – яңгыр* һ.б. Морфологик архаизмнар – грамматик формасы үзгәргән (искергән) сүзләр. Мондыйларга мисал

итеп исемнең *-мыз, -ңыз* тартым кушымчаларын (*раббымыз, йортыңыз*); фигыльләрдә инфинитивның *-мак/-мәк, -мага/-мәгә* (*атламак, кылмак, санламак, түзмәк, үтәмәк; бармага, йөрмәгә*), исем фигыльнең *-ыш/-мыш* (*азмыш, барыш, бармыш, йөреш, килеш*), боерык фигыльнең *-гай/-гәй, -гыл/-гел,...әйлә* (*бармагыл, кылгыл, килгәй, гафу әйлә*), сыйфат фигыльнең *-мыш* (*картаймыш көн, күрмәмеш булды*) формаларын күрсәтергә була.

*Неологизм* (грекча *neos* – яңа, *logos* – сүз) дип телдә аерым бер чорда барлыкка килгән сүзләрне, сүзләрнең мәгънәләрен һәм сүзтезмәләрне атыйлар. Тормыштагы яңа күренеш, төшенчәләрне атау өчен, тел яңа сүзләр исәбенә байый тора. Мондый сүзләр аеруча җәмгыять тормышындагы кискен үзгәрешләр чорында күпләп барлыкка килә. Әйтик, 1917 елгы инкыйлабтан соң татар телендә *совет, комсомол, совхоз, коммунизм, трактор, бишьеллык, колхозчы* кебек бик күп яңа сүзләр туа. XX гасырның 80 нче елларында башланган иҗтимагый-икътисади үзгәрешләр дә лексикага зур йогынты ясады, телебездә яңа төр лексика актив кулланыла башлады: *хәбәрдарлык, шартнамә, үзгәртеп кору, акцияләр, кертем, телефакс* һ.б. Яңа сүзләр, гадәттә, башта мәгълүмат чаралары телендә чагылыш таба, һәм, акрынлап, актив лексикага, гомумкулланышка кереп китә.

## Татар телендә сүзлекләр

Дөньядагы барлык төр сүзлекләрне икегә бүлеп карыйлар: энциклопедик һәм филологик сүзлекләргә. *Энциклопедик сүзлекләрдә* төшенчәгә аңлатма бирелә, алар турындагы карашлар, гипотезалар, фикер каршылыклары чагылдырыла, шушы төшенчәләр белдергән күренешләр, әйберләр, вакыйгалар, затлар турында мәгълүматлар да бирелә. Энциклопедияләрнең универсаль һәм махсус төрләре була. Универсаль энциклопедияләрдә җәмгыять тормышы һәм фәннең төрле тармакларыннан системага салынган мәгълүматлар бирелә. Мәсәлән, Зур Совет энциклопедиясе, Татар энциклопедик сүзлеге һ.б. Махсус энциклопедияләр медицина, авыл хуҗалыгы, физика, техника, педагогика, музыка, әдәбият белеме һ.б. буенча төзелергә мөмкин.

*Филологик сүзлекләрдә* сүзләр, аларның мәгънә үзенчәлекләре, лексик-грамматик сыйфатлары аңлатыла. Максаты, эчтәлеге, сүзлек мәкаләләренең нинди телдә язылуы һ.б. карап, филологик

сүзлекләрнең ике төре була: бертелле һәм тәрҗемәле сүзлекләр. *Бертелле сүзлекләрдә* тел материалы бары тик бер телдә генә тасвирлана. Боларга телләрнең күпчелегендә булган аңлатмалы сүзлекләрне, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләрен, фразеологик сүзлекләрне һ.б. кертеп карыйлар.

*Тәрҗемәле сүзлекләрне,* ничә тел материалы кулланылуга карап, икетелле һәм берничә тел сүзлекләренә бүләләр. *Икетелле сүзлекләр* иң күп таралган сүзлекләрдән санала: русча-татарча, татарча-русча, русча-инглизчә, русча-төрекчә һ.б. *Күптелле сүзлекләрдә* өч-дүрт һәм хәтта аннан да күбрәк телләр янәшә куелырга мөмкин. Мәсәлән, татарча-русча-гарәпчә сүзлек, русча-татарча-инглизчә сүзлек һ.б.

Татар сүзләренең сүзлекләргә теркәлеп, беркетелеп калуы бик борынгы заманнарга карый. Шулардан иң борынгысы – Мәхмүд Кашгари тарафыннан XI гасырда төзелгән «Диване лөгатет-төрк» исемле сүзлек. Төрки телләр сүзлеге булган бу хезмәттә шул замандагы күпсанлы төрки кабиләләрнең тел үрнәкләре, бай фольклор материалы урын ала. Анда аерым шигъри дүртьюллыклар, мәкальләр, әйтемнәр һәм табышмаклар тупланган. Сүзлекнең нигезен төрки сүзләр тәшкил итә. Автор, ул сүзләрнең кулланылышын күрсәтү өчен, китерелгән мисалларга гарәп телендә аңлатмалар биреп бара. Мондагы сүзләрнең, халык авыз иҗаты материалларының шактые хәзерге татар телендә дә яшәп килә.

XIII–XIV гасырлар чигендә гарәп галиме Ибне Мүһанна «Китабе тәрҗемәи фарси вә төрки вә магули» дип аталган сүзлек төзи. Гарәп телендә язылган әлеге хезмәттә төрки телләрнең фонетикасы, морфологиясе хакында мәгълүматтан тыш, йөзләгән лексик берәмлек бирелә. Әлеге сүзлектә теркәлгән фигыльләрнең зур күпчелегенең хәзерге татар телендә дә актив кулланылышта йөрүе сүзлекнең татар теленә якынлыгын дәлилли торган фактларның берсе булып тора[1].

Татар теленең борынгы элементлары «Кодекс Куманикус» (Коман мәҗмугасы) сүзлегендә дә урын ала. Танылган тюрколог В.В. Радлов бу китаптагы коман теленең Идел буе татарлары теленә, аеруча мишәр диалектына якынлыгын әйтә.

---

[1] *Ногман М.* XVII–XVIII йөзләрдәге русча-татарча кульязма сүзлекләр. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1969. Б. 9.

XVI гасырда Казан ханлыгын рус дәүләтенә кушканнан соң, гамәли куллану өчен төзелгән татарча-русча һәм русча-татарча сөйләүлекләр, тәгъбирләр, аңлатмалар һәм сүзлекләр төзелә башлау татар теле лексикасын теркәү юнәлешендә яңа бер этап була. Шундый сүзлекләрдән XV–XVII гасырларга караган тел материалларын, шул исәптән 40 ка якын татар сүзе һәм тәгъбирен туплаган «Памятники старинной русской лексикографии по рукописям XV–XVII веков» (авторы рус галиме П.К. Симон, 1908) хезмәтен һәм билгесез автор тарафыннан төзелгән «Сборник рукописей конца XVII и начала XVIII века» исемле кулъязма җыентыкны атарга кирәк. Соңгы кулъязма эчендә «Наука языку турскому» дип аталган 15 битлек аңлатмалы сүзлекчә бар һәм, рус сүзләренә татарча аңлатма бирелеп, алар «турский», «по-персидски», «по-татарской речи» дигән бүлекләргә аерып күрсәтелә. Бу сүзлекләрнең күбесе – *кулъязма* рәвешендәге белешмәлекләр.

1740 елларда П.И. Рычков төзегән «Русча-татарча-калмыкча сүзлек» тә татар теле шул чор сүзлек составын өйрәнүдә кыйммәтле чыганак ролен үти. XVIII гасырның соңгы чирегендә татар теле рус гимназияләрендә һәм университетларында укытыла башлый. Шул уңай белән күп кенә русча-татарча сүзлекләр дөнья күрә. 1785 елда Сәгыйть Хәлфин 23 000 сүзне эченә алган «Татарский словарь в пользу обучающихся при Казанских гимназиях юношества татарскому языку» дип исемләнгән сүзлек төзегән. 1804 елда Санкт-Петербург шәһәрендә Иосиф Гигановның 682 битле русча-татарча сүзлеге басыла. Болар – татар сүзләрен үз эченә алган беренче *басма* сүзлекләр.

Ибраһим Хәлфиннең 1 600 сүзне үз эченә алган татарча-русча һәм өлешчә русча-татарча сүзлеге 1822 елда «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» дигән китабына кушымта буларак басыла. Казанның дини семинариясендә татар теле укытучысы А. Троянский рус руханилары булып чыгучыларга мөселман дине әһелләре куллана торган иске татар теле нигезендә «Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нём речений арабских и персидских, собранный трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии священника Александра Троянского» исемле ике томлык сүзлек төзи, әлеге сүзлек Казанда басылып чыга (1 том, 1833, 629 б.; 2 том, 1835, 340 б.).

Салихҗан Күкләшевнең 1859 елда Казан университеты типографиясендә басылган «Словарь к татарской хрестоматии» сүзлеге

дә игътибарга лаек (106 б.). Санкт-Петербург университетының Көнчыгыш факультеты доценты Лазарь Будагов «Сравнительный словарь турецко-татарских наречий» исемле бик зур сүзлек төзи, аның I томы Санкт-Петербургта 1869 елда басыла (820 б.), II томы шунда ук 1871 елда чыга (416 б.).

Керәшеннәрне дини уку йортларында укытучылар да керәшен татарларының сөйләшләрен чагылдырган сүзлекләр төзү эшенә керешәләр. Шундый сүзлекләрнең иң күренеклесен Н.П. Остроумов эшләп чыгара. Ул «Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещённых татар Казанской губернии» дип атала. Казан университеты типографиясендә 1876 елда басыла, 145 биттән тора. Моннан тыш, 1892 елда шунда ук «Татарско-русский словарь Н. Остроумова» дигән хезмәт нәшер ителә (250 б.).

XIX гасырның II яртысында татар теленең лексикасын өйрәнүгә һәм туплауга Каюм Насыйри күп көч сарыф итә. 1878 елда аның «Татарча-русча лөгать» исемле 120 битлек китабы дөнья күрә. 1892 елда К. Насыйриның «Рус хөрүф һиҗасе вазәрә мөрәттип лөгать китабы» дигән сүзлеге чыга. 263 битлек әлеге сүзлектә 20 мең сүз теркәлгән. К. Насыйриның татар теленең сүзлек составын өйрәнүгә багышланган әһәмиятле хезмәтләреннән тагын берсе – «Ләһҗәи татари» дигән ике томлы аңлатмалы сүзлек. Бу хезмәт университет типографиясендә басыла: I томы (226 б.) – 1895, II томы (106 б.) 1896 елда дөнья күрә. Шуны искәртү кирәк: татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзү идеясен 1829 елда ук Казан университетында гарәп һәм фарсы телләре укытучысы профессор Франц Эрдман күтәреп чыга, аның проекты университет советында уңай бәя ала, ләкин бу идея ул чорда кадрлар булмау аркасында реальләшми кала. Билгесез авторның «Краткий татарско-русский словарь с прибавлением некоторых славянских слов с татарским переводом» китабы 1880–1891 еллар арасында биш мәртәбә басыла. 1894 елда А.А. Воскресенский «Русско-татарский словарь с предисловием о произношении и этимологических изменениях татарских слов» дип аталган 374 битлек сүзлек бастыра.

XX гасыр башында дөнья күргән сүзлекләр күләме һәм лексик фондның тулылыгы белән аерылып тора. 1913 елда С. Рахманколый һәм А. Карам 35 000 сүзне эченә алган «Полный русско-татарский словарь с указанием ударений и грамматических свойств каждого языка, со включением иностранных слов, вошедших

в употребление в русском языке» дигән сүзлек чыгаралар. Әлеге сүзлек, И. Кулиев һәм Т. Мәмлиев тарафыннан эшкәртелеп, 1920 елда тагын нәшер ителә. XX гасырның 20 нче елларында аңлатмалы сүзлек төзү эшен Җамал Вәлиди күтәреп ала һәм «Татар теленең тулы сүзлеге» исеме астында 1927 елда аның беренче томын һәм 1929 елда икенче томының беренче өлешен чыгара. Бу чыганаклар татар теленең сүзлек байлыгын, семантик үзенчәлекләрен өйрәнүдә алыштыргысыз байлык вазифасын үтиләр һәм татар лексикологиясе фәне формалашуның башлангыч этабы булып торалар.

XX гасырның 40 нчы елларыннан фәнни яктан эшкәртелгән һәм билгеле бер системага салынган сүзлекләр төзелә башлый, алар телнең лексик байлыгын өйрәнүдә төп чыганак ролен үти. Шундыйлардан 1938–1951 еллар арасында Г. Нугайбәк, Ф. Әмирхан, М. Корбанов, С. Фәйзуллин, Р. Газизов, М. Гыймадиев тарафыннан төзелгән татарча-русча сүзлекне, 1966 елда Мәскәүдә «Совет энциклопедиясе» нәшриятында Г.С. Әмиров, А.Ш. Әсәдуллин, У.Ш. Байчура, Ш.С. Ханбикова редакцияләгән, соңрак Ш.С. Ханбикова һәм Л.Т. Мәхмүтова тарафыннан кабат редакцияләнгән «Татарча-русча сүзлек»не атарга кирәк.

XX гасыр урталарыннан сүзлекләр төзү эшен Тел, әдәбият һәм тарих институты (1993 елдан – Тел, әдәбият һәм сәнгать институты – ТӘһСИ) башкарып килә. Институт галимнәре тарафыннан төзелгән күп томлы сүзлекләрдән дүрт томлы русча-татарча сүзлекне билгеләп үтү зарур. Аның беренче томы Р. Газизов, М. Гыймадиев тарафыннан 1955 елда чыгарыла (359 б.), икенче томы Р.С. Газизов, Л.Т. Мәхмүтова, Ә.М. Ахунҗанов, Ф.М. Газизова тарафыннан төзелә һәм 1956 елда нәшер ителә (448 б.) өченче томын Р.Ф. Шакирова, Э.М. Ахунҗанов, Л.Т. Мәхмүтова, Ф.С. Фәсиев төзиләр, бу том 1958 елда дөнья күрә (483 б.), дүртенче томы Ә.М. Ахунҗанов, Л.Т. Мәхмүтова, Р.Ф. Шакирова, Ф.С. Фәсиев, Р.Ш. Шәкүров, Г.С. Әмиров тарафыннан 1959 елда чыгарыла (448 б.). 1971 елда 50 000 сүз кергән 803 битле русча-татарча бер томлы сүзлек төзелә. 1984 елда «Русский язык» нәшриятында Ф.Ә. Ганиев редакциясендә русча-татарча сүзлек дөнья күрә (736 б.). Әлеге сүзлек 1985, 1991, 1997 елларда кабат нәшер ителә. 1988 елда И.А. Абдуллин, Ф.Ә. Ганиев, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.А. Юналееваның 25 мең сүзне эченә алган татарча-русча сүзлеге басылды, 1995 елда ул кабат нәшер ителде.

Тел, әдәбият һәм тарих институты аңлатмалы сүзлек төзүгә аерым әһәмият бирә һәм аны өч томда чыгаруга ирешә: 1 том – 1977 елда (476 б.), 2 том – 1979 елда (728 б.), 3 том 1981 елда (832 б.) чыга. 2005 елда ТӘһСИнең лексикография бүлеге Ф.Ә. Ганиев (баш ред.) К.С. Миннибаев, Ф.М. Газизова, Г.Г. Саберова, Ф.Ф. Гаффаровалар редакциясендә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н яңартып чыгарды. Ул – 848 биттән торган һәм 58 000 гә якын берәмлекне туплаган бер томлы хезмәт. Шушы аңлатмалы сүзлек нигезендә 2013 елда «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» дөнья күрә. Сүзлектә 10 меңнән артык лексик берәмлек урын алган.

Бүгенге көндә ТӘһСИнең лексикография бүлеге яңа аңлатмалы сүзлек төзү процессында. Алтытомлык итеп планлаштырылган бу фундаменталь характердагы сүзлекнең биш томы: I томы (712 б.) – 2015, II томы (748 б.) – 2016, III томы (744 б.) – 2017, IV томы (760 б.) – 2018, V томы (908 б.) – 2019 елларда басылып чыкты. Чама белән 12 000 сүзне колачлаган VI том да быел нәшер ителәчәк. Лексикографик хезмәтне төзүдә күп кенә лексикографлар катнашты: Р.Р. Абдуллина, Ю.Ф. Борһанова, Ф.М. Газизова, А.Ф. Гайнетдинова, О.Н. Галимова, Ф.Ф. Гаффарова, Ф.А. Кушелекова, А.М. Сәгыйтова, Г.Г. Саберова, И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Г.Р. Сәмирханова, Р.Т. Сәфәров, Ф.И. Таһирова, А.А. Тимерханов, Г.Д. Фәтхетдинова, Л.Ш. Шәмсетдинова. Бу сүзлек башкалардан күләме, сүз саны белән генә түгел, үзенең бай эчтәлеге, материалның структур төзелеше белән дә аерылып тора. Аны төзегәндә татар һәм төрки лексикографиянең соңгы казанышлары да исәпкә алынган. Бүгенге көндә ул – татар әдәби теленең лексикасын чагылдырган иң тулы, иң бай сүзлек буларак кабул ителә.

2007 елда ике томлы татарча-русча сүзлекнең чыгуы татар тел гыйлеме, аерым алганда лексикологиясе үсешендә бик зур бер уңышлы адым булды. Сүзлек үз эченә 56 мең сүзне, 7400 фразеологик берәмлекне ала. Күләме: 1 том – 725 бит, 2 том – 727 бит.

Профессор Р.Г. Әхмәтьяновның фундаменталь характердагы ике томлы «Татар теленең этимологик сүзлеге» (2015) эшләнеп нәшер ителү – төрки-татар дөньясында күптән көтеп алынган игътибарга лаек зур вакыйга булды. Анда татар телендәге 10 300 гә якын сүз теркәлеп, аларга аңлатмалар бирелгән, 200 дән артык тел һәм диалект материаллары чагылыш тапкан.

2018 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан 80 000 сүзне үз эченә алган ике томлы «Русча-татарча сүзлек» нәшер ителде. Әлеге белешмәлекне төзекгәндә яңа рус аңлатмалы сүзлекләрен төзү тәҗрибәсеннән чыгып эш ителде, шулай ук терминологик лексикографик хезмәтләр файдаланылды.

Шулай ук тел белеме буенча сүзлекләрне эшләп бастыру эше бик мөһим. Соңгы елларда татар телендә төрле типтагы сүзлекләр эшләнде. Бүгенге көндә дөрес язу һәм дөрес әйтелеш кагыйдәләрен беркетергә тиешле орфографик һәм орфоэпик сүзлекләр эшләүгә дә аерым игътибар бирелә. «Татар теленең орфоэпик сүзлеге» (2019), «Татар теленең кыенлыклар сүзлеге» (2019) дөнья күрде. Татар теленең орфографик сүзлеге»н төзү буенча эш бара. Шулай ук дистәләгән терминологик сүзлекләр нәшер ителеп килә.

Хәзерге көндә татар теле лексикасын өйрәнүдә электрон сүзлекләр, татар теленең «Туган тел» милли корпусы һәм татар телендәге электрон текстларны туплаган татар теленең язма корпусы да әһәмиятле чыганак булып тора. Югарыда саналган һәм биредә аталмаган, әмма татар теленең сүзлек составын, аның үсеш-үзгәрешен, кулланылыш үзенчәлекләрен эзлекле һәм комплекслы өйрәнүгә нигез булган чыганаклар татар лексикологиясе фәненең бүгенге дәрәҗәсен һәм үсеш юнәлешләрен билгеләгәндә зур роль уйныйлар[1].

Соңгы елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «Сүзлекләрнең электрон фонды» (http://www.antat.ru/ru/tatzet) булдырылды. Фондка институтта моңа кадәр чыккан басмалар һәм төзелеп килгән һәрбер лексикографик чыганак урнаштырыла бара. Бер яктан, бу соңгы елларда чыккан иң яңа сүзлекләрне бер урынга туплау булса, икенче яктан, андагы материал кызыксындыра торган сүзнең төрле чыганакларда бирелешен күзәтергә, аның язылышын, әйтелешен, мәгънәләрен, килеп чыгышын, тәрҗемәләрен һ.б.ны күрергә мөмкинлек бирә.

[1] Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. Б. 15–20 .

## IV БҮЛЕК

# ТЕЛЛӘРНЕ САКЛАУ МӘСЬӘЛӘСЕ

### Татарларда мәгариф системасы һәм тел белеме өлкәсендәге эшчәнлек

Татар халкының борынгыдан укымышлы булуы, гыйлем-мәгърифәткә ихтирам белән каравы төрле чыганаклар аша мәгълүм. Кытай һәм гарәп язма истәлекләре әле Төрки каганат чорында ук төркиләрдә мәгарифнең дәүләти системасы яшәгәнлеге турында хәбәр итә. Бу традиция дәвамлы булып, соңгырак чор төрки дәүләтләрдә дә тукталып калмый. Мәгариф бигрәк тә мөселман мәдәнияте контекстында зур үсешләргә ирешә. Борынгы төрки чорларга караган күпсанлы табылдыклар төрки-татар халкында укый-яза белү дәрәҗәсе югары булуын дәлилли.

X гасыр башы гарәп сәяхәтчесе Ибне Рустә истәлекләрендә дә болгарларның ислам динен тотуы, авылларда мәчетләр һәм башында мәзин һәм имамнар торган башлангыч мәктәпләр булуы искә алына. X гасырда ислам дөньясына рәсми кабул ителеп, Идел буе болгарлары гарәп-мөселман дөньясының иң соңгы фән һәм мәгариф казанышлары белән танышалар. Болгарларның Биләр, Болгар, Сувар шәһәрләре эре мәгърифәт үзәкләре булып танылa. Шул рәвешле Идел буе Болгар дәүләтендә Шәрыктагы заманы өчен иң алдынгы фән һәм мәдәният өлгеләрен үзләштергән галимнәр барлыкка килә башлый.

Алтын Урда дәүләтендә татарларның мөселман мәгариф системасы яңа бер үсеш этабына керә. Укымышлылыкка игътибарның тагын да артуына дәүләттә мәдәният һәм мәгариф учаклары булып хезмәт иткән шәһәрләрнең күплеге сәбәпче. Үргәнеч, Солхат,

Болгарда, Идел буенда калыккан яңа калалар – Сарай, Сарай әл-Җәдид, Үкәк кебек шәһәрләрдә мәгърифәт үзәкләре булган мәдрәсә һәм мәктәпләр үз эшчәнлеген дәвам итә.

Әстерхан, Казан, Кырым ханлыклары чорына мәгърифәт өлкәсе берничә гасырлык тәҗрибә белән аяк баса. Бу дәвердә мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән, нигездә, дин әһелләре шөгыльләнә. Мәсәлән, Казанда төп мәдрәсә Җамигъ мәчете янында, Хан сарае белән янәшә булып, аны ханлыктагы мөселманнарның башлыгы – сәед Колшәриф җитәкли. Татар авылларындагы мәчет каршында эшләп килгән мәктәп яки мәдрәсәләрдә мөгаллимнәр, китап күчереп язучылар, галимнәр, шагыйрьләр, дин белгечләре һәм дәүләт эшлеклеләре әзерләнә.

XVI–XVII гасырларда, татарның дәүләт идарәсе җимерелү белән, башында мөселман дин әһелләре торган мәгариф системасы татар телен һәм мәдәниятен саклау вазифаларын үз өстенә ала. Бу чорда нәкъ менә дин белгечләре, мәгърифәт таратучылар булып, татар рухи дөньясын саклыйлар. Җирле халык мөселман җәмгыятьләрендә, ягъни мәхәллә тарафыннан тәэмин ителеп торган авыл мәктәпләрендә һәм зур булмаган мәдрәсәләрдә башлангыч белем алуын дәвам итә. Биредә укучылар уку-язуны, ислам кагыйдәләрен үзләштерәләр. Татарларда соңрак кадими дип аталган традицион мөселман белем бирү системасы хасил була.

XVI гасырның икенче яртысы – XVIII гасырларда татарлар арасында суфичылык киң тарала. Белем бирү шәех-мөрид чылбыры рәвешен ала, остазы шәехкә мөриднең берсүзсез буйсынуына корылган кырыс тәртипләр һәм ябык тарикатьләр урнаша. Суфичылык асылда мөселман өммәтен берләштерә һәм авыр шартларда мөселман уку-укыту системасын саклый һәм үстерә. Әмма Урта гасырлардан килгән стереотипларны саклау һәм иске ысулларга гына таянырга омтылу аңа көчәеп үсәргә комачаулый.

Екатерина II чорында патшабикә тарафыннан бирелгән дин иреге сәясәте татарларны янә активлаштыра. Бик тиз һәм күпләп мәчетләр салына, яңа мәктәп-мәдрәсәләр ачыла. Бу этапта, ягъни XVIII йөз ахыры – XIX йөз башында татарларда халык мәгарифенең бөтен бер системасын төзүгә юл ачыла, мәгариф системасы татар җәмгыятендә яңа идеяләр тарату өчен интеллектуаль базага әверелә. Татар дини-фәлсәфи фикере бу чорда кәләмне һәм суфичылыкның мораль-этик нормалары белән керешкән теологияне тәнкыйтьли.

XIX гасырның икенче яртысы татар дини реформаторларының казанышлары аларның дини карашны һәм әхлакый мәсьәләләрне дөньяви ихтыяҗларга туры китереп яңартуларында, ислам гыйлеменең эчтәлегенә заман күзлегеннән якын килергә тырышуларында, дини һәм дөньяви белем бирүнең прогрессив формаларын кулланышка кертүләрендә чагыла. Мәдәниятне һәм җәмгыятьне үзгәртүгә юнәлтелгән әлеге иҗтимагый-сәяси хәрәкәт Россия мөселманнары арасында җәдитчелек дигән исем ала. Хәрәкәтнең мәдәни үзәкләре – Казанда «Мөхәммәдия», Уфада «Галия» һәм «Госмания», Оренбургта «Хөсәения», Троицкида «Рәсүлия», Әстерханда «Низамия», Иж-Бубый авылында Буби мәдрәсәләре үз эшчәнлекләрен җәелдерә.

XIX гасыр ахырына татарларда Европа мәдәниятенә якынаю һәм тормышны Яңа заман таләпләренә туры китереп үзгәртеп кору омтылышы барлыкка килә. Яңарыш татар мәдрәсәләрендә традицион укыту методларын үзгәртүдән башлана. Алга таба укыту системасын Россия, Европа, Америка һәм Төркия педагоглары тәҗрибәсе нигезендә реформалауга йөз тотыла. Чит илләр мәгарифе казанышлары, укытуның яңа методлары һәм алымнары татар вакытлы матбугатында актив пропагандалана һәм алар мәдрәсәләр өчен яңа программа-дәреслекләр әзерләгәндә мөгаллимнәр тарафыннан актив файдаланыла.

Мәдрәсәләрдә сыйныфларга бүлеп, төркемләп, билгеле бер программа һәм төгәл билгеләнгән җәдвәл буенча укыту тәртибе кертелә, аерым китаплар укудан предметлар өйрәнүгә күчелә. Беренче тапкыр татар теле һәм әдәбияты, тарих һәм география, табигать фәннәре укытыла башлый. Мәдрәсәләрдә дөньяви предметлар дини белем һәм тәрбия белән янәшә бара. Укыту берничә баскычка бүленә. Мәсәлән, атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә ул башлангыч (ибтидийя) – әзерлек сыйныфы һәм 5 ел уку, урта (рөшдия) – 6 ел уку, югары 3 еллык (галия) баскычлары булдырыла. 1912/13 уку елыннан урта баскычка алдынгы урта (игъдадия) өстәлә, аны тәмамлаганнар мөгаллим булып эшләү хокукы ала.

Мәдрәсәнең югары баскычына күчкән шәкертләр татар башлангыч уку йортларында белем бирә. Кагыйдә буларак, җәйге каникул вакытларында алар авыл балаларын укырга-язарга өйрәтү белән шөгыльләнә. Кырым, Казан, Оренбург җәдит мәдрәсәләрен тәмамлаган шәкертләр Идел-Урал буенда гына түгел, Себердә,

Казакъстанда, Урта Азия һәм Кавказда төрки халыклар арасында мәгърифәт тарату белән шөгыльләнә.

XIX гасыр ахырына чит ил һәм Россия уку йортларын тәмамлаган зыялылар (Й. Акчура, С. Максуди (Сорбонна), Ф. Бакиров (Нью-Йорк) һ.б.) җәмгыятьтәге яңарыш хәрәкәтен җитәкли. 1906 елдан хатын-кызлар да Казан университетында уку хокукына ирешә. Санкт-Петербург, Мәскәү шәһәрләренең төрле профильле Югары курсларында укыган татар кызлары чит илләргә китеп белем эстәүләрен дәвам итә: З. Абдрахманова һәм С. Сыртланова Женевада укый. С. Шакулова Сорбоннада – диплом, аннары механика профессоры гыйльми дәрәҗәсен ала. Дистәләрчә татарлар Париж, Женева, Льеж, Лейпциг, Фрайбург, Нью-Йорк, Токио, Истанбул университетларында укый. Укып бетереп, алар гыйлем багажы һәм татар җәмгыятен үзгәртү, шул исәптән милли мәгариф системасын камилләштерү идеяләре белән туган илгә әйләнеп кайталар.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына татарларда милли мәгариф системасы тулысынча мөстәкыйльлеккә ирешә, финанс һәм эчтәлек ягыннан дәүләттән бәйсез булып әверелә. XX йөз башына татарларда һәр теләгән кешегә белем алу мөмкинлеге булдырыла.

Алга таба 1917 елгы Октябрь вакыйгалары Россия халыклары тормышына кискен үзгәрешләр алып килә. Хөкүмәт кабул иткән беренче хокукый актлар җәмгыятьтә диннән аерылу сәясәтенә юл ача. Динне дәүләттән аеру, дин әһелләрен өстенлекләрдән мәхрүм итү, гаилә мәсьәләләрен хәл итүне һәм белем бирүне дөньяви дәүләт карамагына тапшыру күзәтелә. Зур үзгәрешләр булуга карамастан, татарларның милли мәгариф системасында дәвамчанлык бөтенләй югала дип әйтеп булмаса да, бу чорда милли мәгариф шактый нык кризис кичерә. Бу чордан башлап, иң эре татар җәдит мәдрәсәләре, мәктәпләр югары һәм махсуслаштырылган педагогика уку йортлары итеп үзгәртелә. XX гасырның 30 нчы елларыннан Россия татар-мөселманнарының дөньяга исламча карашлары гомумән шик астына алына, үз традицияләре гасырлар буена формалашкан мөселман җәмгыяте авырлыклар алдында кала, белем-мәгърифәт учагы вазифаларын үтәп килгән мәчетләр ябылып, аларның эшчәнлеге чикләнә, халыкның дини һәм милли традицияләрен аерып карау тенденциясе барлыкка килә.

Яңа совет мәктәбе төзелеп, 1960 еллар башыннан уку-укытуда рус теленә күчү башлана. Бу чорда татар мәгарифенең миллилеге

уку предметларын туган телдә укытуда саклана, әмма татарча укыту, нигездә, Татарстан авылларында гына башкарыла. Дәүләт оешмаларында, эш кәгазьләрендә, урта һәм югары уку йортларында рус телен куллануга өстенлек бирелү сәбәпле, татарлар арасында туган телне түгел, ә рус телен камилрәк үзләштерергә омтылыш көчәя, мондый тенденция аеруча шәһәрләрдә күзәтелә.

80 нче еллар ахыры – 90 нчы еллар башыннан милли мәктәпкә мөнәсәбәт уңай якка үзгәрә. Татарстанда күпләп татар мәктәпләре һәм гимназияләре ачыла, югары уку йортларында татар кафедралары оеша. XX–XXI гасырлар чигендә Татарстанда милли телләр һәм мәдәниятләрне үстерүгә яңа мөмкинлекләр туа, ул милләтара һәм динара дустанә мөнәсәбәтләрне саклау өчен нигез ролен үти. Шәһәрләрдә һәм авылларда милли мәктәпләр үз эшен яңарта, башка милләт балалары үз туган телләрен якшәмбе мәктәпләрендә өйрәнә. Милли телләрне һәм гыйлемнәрне югары уку йортларында (бигрәк тә Казан (Идел буе) федераль университетында) үзләштерү өчен шартлар тудырыла. 1993 елдан Татарстанда төрле юнәлештәге институтларны берләштергән Фәннәр академиясе эшли башлый. Бу этапта татар халкы тарихында рухи яңарыш һәм мәгарифнең бергә кушылып, бер-берсен тулыландыруы күзәтелә. Бу этапта татар халкы тарихында рухи яңарыш һәм мәгарифнең бергә кушылып, бер-берсен тулыландыруы күзәтелә. Дини һәм дөньяви белем бирү системалары XIX гасыр ахырында ук бер-берсеннән аерылган булуга карамастан, мәгариф системасына тыгыз керешкән рухи кыйммәтләр, милләтнең дә, аерым кешенең дә цивилизацияле күзаллавына юнәлеш биреп, татар халкының үсешен билгеләүдә катнашуын дәвам итә, бу исә милләтнең бердәмлеген тәэмин итә.

Бүгенге көндә Казан (Идел буе) федераль университеты – милли мәгариф һәм филолгия өлкәсендә әйдәп баручы учреждение. Ул Россиядәге иң борынгы уку йортларыннан санала. 1804 елның 5 ноябрендә император Александр I Казан Император университетының Раслау Грамотасына һәм Уставына кул куя. Университет ачылгач ук, аның Көнчыгыш бүлегендә, гарәп һәм фарсы телләре белән беррәттән, татар теле укытыла башлый. Н. Лобачевский, С. Аксаков һ.б. күренекле кешеләрнең остазы – университетның беренче укытучыларыннан берсе – татар кешесе Нигъмәт Ибраһимов була. Профессор И. Березин, А. Казембек,

Х. Френ, Карл Фукс һ.б. галимнәр Көнчыгыш бүлегендә эшлиләр. Рус һәм чит ил галимнәре белән бергә И. Хәлфин, М. Мәхмүдов кебек алдынгы карашлы татар укымышлылары университетка эшкә тартыла.

XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасыр башында университет галимнәре Н. Ильминский, В. Радлов, Н. Катанов һ.б. тюркология өлкәсендә җитди тикшеренүләр алып баралар, татар телен өйрәнәләр.

XX гасыр башында мәдрәсәләрдә ана теле буларак укытыла башлаган татар теле (бу өлкәдә Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, М. Корбангалиев һ. б. татар галимнәренең роле зур) 1920 еллар башында Казан университетына үтеп керә, һәм аның йөз еллык тәҗрибәсенә нигезләнеп, биредә яңадан өйрәнелә башлый. 1920–1930 елларда татар теле университетта икенче дәүләт теле буларак укытыла, бу эшкә М. Корбангалиев җитәкчелек итә.

1944 елда КДУның тарих-филология факультеты эчендә татар теле һәм әдәбияты бүлеге оеша. 1989 елда Казан дәүләт университетының Зур советы карары нигезендә татар филологиясе, тарихы һәм Шәрык телләре факультеты мөстәкыйль структура буларак эшли башлый. 2000 елда Көнчыгыш телләр бүлеге мөстәкыйль бер институт булып оешкач, факультет татар филологиясе һәм тарихы факультеты дип үзгәртелә. 2011 елда Казан федераль университетында Филология һәм сәнгать институты төзелеп, төрле гыйльми һәм педагогик үзәкләрнең көчләре бергә туплану җирлегендә, татар телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен өйрәнү яңа дәрәҗәгә күтәрелде. Бүгенге көндә Габдулла Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология Югары мәктәбе татар теле һәм башка төрки телләрне һөнәри дәрәҗәдә үзләштергән, аларның әдәбиятын һәм мәдәни кыйммәтләрен яхшы белгән бакалаврлар һәм магистрлар әзерли.

Татарстан Республикасы төзелү уңаеннан 1920 елның маеннан милли мәгарифтә тикшеренү өлкәләре күпкә киңәя, махсус фәнни-тикшеренү җәмгыятьләре һәм үзәкләре барлыкка килә. Алар арасында 1921 елда Мәгариф халык комиссариаты каршында оештырылган Академик үзәк аерым урын алып тора. Үзәкнең беренче рәисе итеп Г. Максудов (1922–1924) билгеләнә. Аннан соң бу вазифаны Г. Ибраһимов (1929 елга кадәр), С. Атнагулов (1929–1930 еллар) башкара. Анда эшләгән хезмәткәрләр арасында Е. Чернышев, Н. Фирсов, М. Худяков, Г. Гобәйдуллин,

М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Г. Рәхим, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, М. Фазлуллин кебек атаклы галимнәрнең исемнәрен атарга мөмкин. Үз тирәсенә галимнәрне туплаган әлеге үзәк тарафыннан «Татар халкын өйрәнү фәнни җәмгыяте хәбәрчесе» һәм «Татарстан» журналлары чыгарыла, төбәк тарихын, татар әдәбияты һәм теле тарихын, терминология һәм орфография мәсьәләләрен өйрәнү, халык авыз иҗаты үрнәкләрен җыю һәм бастырып чыгару, сүзлекләр һәм мәктәпләр өчен дәреслекләр төзү буенча актив эшчәнлек алып барыла.

Алга таба Академик үзәктә эшләгән галимнәрнең күбесе фәнни эшчәнлекләрен Тел һәм әдәбият татар фәнни-эзләнү институтында (бүгенге көндә – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) дәвам итәләр. Татар теле һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институтын оештыру турында карар 1937 елның 16 апрелендә ТАССР ҮБК Президиумы тарафыннан кабул ителә. 1939 елның 7 октябрендә Институт үзенең эшчәнлеген башлап җибәрә. Директор вазифалары Укытучыларның квалификациясен күтәрү институты җитәкчесенең укыту эшләре буенча урынбасары М.А. Нигъмәтуллинга йөкләнә.

1946 елның гыйнварында СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы оештырылу уңаеннан, Институт академия составына кертелә һәм СССР Фәннәр академиясе фәнни оешмасына әверелә. 1967 елда Институтка татар әдәбияты классигы, галим һәм педагог, җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов исеме бирелә. 1993 елның башында Тел, әдәбият һәм тарих институты 1991 елның ахырында – 1992 елның башында оештырылган Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе карамагына тапшырыла. Башта Россия Фәннәр академиясе, соңыннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе карамагындагы Институтның фәнни хезмәткәрләре саны арта, аспирантлар кабул итү эше алга китә, аның базасында яңа мөстәкыйль институтлар ачу мөмкинлеге туа. 1993 елда Институтның татар энциклопедиясе бүлеге нигезендә Татар энциклопедиясе институты, 1996 елда аерылып чыккан биш бүлек (тарих, археология, этнография, иҗтимагый фикер, тарих һәм мәдәният һәйкәлләре үрнәкләре бүлекләре) хисабына Тарих институты оештырыла. Аларга нигез булган Тел, әдәбият һәм тарих институты Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты дип атала башлый.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты төзелгәнннән алып бүгенге көнгәчә татар милли мәгарифе үсешен киң колач белән эзлекле һәм дәвамчан алып бара. Бүген Институт Татарстан Республикасында һәм аннан читтә татар филологиясе һәм сәнгать белеме өлкәләрендә фундаменталь фәнни тикшеренүләрне координацияләүче төп гыйльми үзәк булып тора. Институтның максаты – татар филологиясе һәм сәнгать белеме өлкәсендә фәнни эшчәнлекне тормышка ашыру; фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр үткәрү, фәнни кадрлар әзерләү. Институтта татар теленең тарихы һәм хәзерге торышы, икетеллелек, татар әдәбиятының күпгасырлык тарихы, текстология һәм археография, татар халык иҗаты, театр, музыка һәм сынлы сәнгатьнең актуаль проблемалары тикшерелә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе каршындагы Гамәли семиотика институты – шулай ук милли мәгариф һәм татар телен өйрәнү өлкәсендә әһәмияткә ия оешма, аның эшчәнлеге татар теленең сөйләм технологияләрен булдыруга юнәлтелгән. 1993 елның 1 июлендә оешкан Институт компьютер системаларын локальләштерү, лингвистик мәсьәләләрне чишү өстендә эзлекле эшчәнлек алып бара. 1998 елдан институт татар теленең сөйләм синтезаторын булдыру өлкәсендә эшли башлый. Институт тарафыннан Windows NT 5.0, Office-2000, Windows-2002, Office-2002 татар локальләштерүе булдырыла һәр кулланучы компьютер системасын тулаем татар телендә куллану белән тәэмин ителә. Шулай ук 2000 елларда институт латин әлифбасына күчү өчен мөмкинлекләр тудыра. 2018 елның ахырында «Смарткат» беренче ярымавтоматик рус-татар сүзлеге гамәлгә кертелә башлый. Сүзлек норматив-хокукый актларны, боерык-карарларны автоматик рәвештә татар теленә күчерүгә юнәлтелгән.

Татар мәгарифе өлкәсендә игътибарга лаек янә бер оешма – Алабуга дәүләт педагогика университеты 1939 елда Укытучылар институты буларак ачыла. 2011 елдан Алабуга институты Казан Идел буе (федераль) университетының бер филиалы булып исәпләнә.

1990 елда шулай ук Яр Чаллы дәүләт педагогия институты студентлар өчен ишекләрен ача. Институтта барлыгы җиде факультет эшли башлый, шул исәптән филология факультеты да оеша. Күп кенә факультетларда белем бирү татар телендә алып барыла, бу исә

авыл җирлегендә урнашкан мәгариф оешмаларын туган телләрен яхшы белгән белгечләр белән тәэмин итү максатыннан чыгып башкарыла.

2011–2015 елларда ул Яр Чаллы дәүләт социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты дип атала. 2018 елдан – Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты. Университетта татар теле һәм әдәбияты, туган телне укыту методикасы буенча зур эшчәнлек алып барыла.

Татарстаннан читтәге оешмалардан Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы үз эшен 1950 елда, К.А. Тимирязев исемендәге Башкорт дәүләт педагогия институты чорында башлый. 1958 елдан БДУның татар филологиясе һәм әдәбияты кафедрасы буларак эшли. Төрле елларда кафедрада танылган галим-мөгаллимнәр С. Поварисов, Б. Сәлимгәрәева, З. Заһидуллина, Р. Мөхәммәтҗанов, Ә. Нигъмәтуллин, Ү. Гыймадиев, Р. Сибәгатов, Ф. Хатипов, В. Исхаков, С. Хафизов һ.б. хезмәт куя.

Кафедра каршында Галимҗан Ибраһимов исемендәге татар фольклоры фонды булдырыла. Үз тарихында кафедра бик күп танылган татар теле һәм әдәбияты белгечләре, шулай ук журналистлар, мөхәррирләр, радио-телевидение хезмәткәрләре әзерләп чыгара.

М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетының филология факультетында татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләнә башлау зур әһәмияткә ия. Биредә 1991 елда татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ачыла. Аның беренче мөдире итеп филология фәннәре кандидаты, доцент Л.Г. Хәбибов сайлана. Соңрак кафедра белән филология фәннәре кандидаты, профессор С.Г. Сафуанов, филология фәннәре кандидатлары, доцентлар С.Г. Хафизов һәм Ф.А. Гафурова җитәкчелек итәләр. Хәзерге вакытта кафедра мөдире вазифасын филология фәннәре докторы, профессор И.С. Насипов башкара. 2012 елда кафедра каршында туган (татар) тел, әдәбият һәм мәдәният яшәешен һәм үсешен өйрәнү фәнни-тикшеренү лабораториясе ачыла. Лабратория Башкортстан Республикасында яшәүче татарларның рухи мәдәниятен һәм этномәдәни үсешен киң яссылыкта фәнни өйрәнә.

Татар телен өйрәнүнең мөһим үзәге буларак Башкорт дәүләт университетының Стәрлетамак филиалы башкорт һәм төрки

филологиясе факультетының татар һәм чуваш филологиясе кафедрасы эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Бу кафедра 1997 елда Стәрлетамак дәүләт педагогия институтының филология факультетында татар-рус (1993 елдан ачылган) һәм чуваш-рус (1994 елда ачылган) бүлекләрендә туган тел укытучылары әзерләүдә уку-укыту һәм гыйльми-методик эшне оештыру максатында ачыла. Кафедрага 1997–2012 елларда И.С. Насипов җитәкчелек итә, хәзерге вакытта мөдир вазифасын И.С. Мансуров башкара. Кафедра татар филологиясен үстерүгә зур өлеш кертә. Андагы галимнәрнең тикшеренүләре татар лексикологиясе, лингвокультурологиясе, стилистикасы һәм тел бәйләнешләре, шулай ук борынгы татар әдәбияты, чит илдә татар әдәбияты һәм төбәк татар әдәбияты мәсьәләләрен өйрәнүгә багышланган.

Башкорт дәүләт университетының Бөре филиалы филология һәм мәдәниятара багланышлар факультетының башкорт, татар һәм мари филологиясе кафедрасы – шулай ук озак еллар дәвамында татар телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен өйрәнү үзәкләренең берсе булып, уңышлы эшләп килде. Бу кафедра 1998 елда филология факультетында рус-мари (1993 елдан ачылган), рус-татар (1995 елдан ачылган) һәм рус-башкорт (1996 елдан ачылган) бүлекләрендә туган тел укытучылары әзерләү максатында оештырылган иде.

1922 елда Төмән педтехникумы составында татар бүлеге ачыла, 1934 елда ул Тубылга күчерелә. 1955 елга кадәр бу уку йорты (педучилище) Көнбатыш Себер мәктәпләре өчен мең ярымнан артык укытучы әзерләп чыгара. 1950 елда Төмән пединститутында татар теле һәм әдәбияты факультеты эшли башлый. 1953 елда ул Тубыл педагогия институтына күчерелә. Ике елдан соң аның составына биредәге педучилище дә кертелә. Узган гасырның 50 –60 нчы елларында биредә Ә. Нигъмәтуллин, Г. Әхәтов, Ф. Хатипов, Г. Саттаров, А. Әхмәдуллин кебек киләчәктә фән докторлары, профессорлары булачак галимнәр эшли. 60 нчы елларның урталарында ябылган бу факультет (бүлек рәвешендә) 1992 елдан кабат торгызыла һәм милли кадрлар әзерләү юнәлешендә озак еллар дәвамында нәтиҗәле эшләп килә. Анда укыту-тәрбия һәм фәнни эшләрне нәтиҗәле алып баруда озак еллар буе Ф. Сәйфуллина күп хезмәт куя. 1993 елда Төмән дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла һәм 2010 елларга кадәр эшли.

1990 елда «Татарстан Республикасының мөстәкыйльлеге турында» Декларация кабул ителү яңа тел сәясәте формалашуга китерде. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасында рус һәм татар телләре Татарстан Республикасының бертигез дәүләт телләре статусына ия.

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 1992 елның 8 июлендә кабул ителә. Ул барлыгы 6 бүлектән, 27 статьядан тора. Закон Татарстан Республикасы халыкларын, аларның мәдәниятләрен һәм телләрен һәрьяклап үстерү, җәмгыятьнең икътисади һәм рухи-әхлакый алга китешендә һәр халыкның иҗади куәтен, йолаларын һәм гореф-гадәтләрен мөмкин кадәр күбрәк куллану, кеше хокукларын гамәлгә ашыру зарурлыгына нигезләнеп эшләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең эшләвен тәэмин итү, Татарстан Республикасында дәүләт телләрендә һәм башка телләрдә әдәбият бастырып чыгаруга ярдәм итү, Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының тел культурасын камилләштерү максатында, мәгариф системасын үстерү һәм башка юнәлешләр күздә тотыла.

1990 еллардан башлап, милли мәгариф өлкәсендә бик күп эшләр башкарылды. Норматив-хокукый база булдыру, яңа мәктәпләр, гимназияләр, лицейлар ачу, Россиянең төрле уку йортларында татар теле һәм әдәбияты белгечләре әзерли торган бүлекләр булдыру һ.б. шундыйлардан.

Соңгы елларда Россия мәгариф системасында милли телләрне укытуга карата куелган таләпләр яңа бер этапның барлыкка килүенә этәргеч булды. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры китереп, татар һәм рус телләрендә белем бирү оешмалары өчен «Туган тел (татар теле)», «Татарстан Республикасының дәүләт теле – татар теле», «Туган телдә (татар телендә) әдәби уку», «Туган телдәге (татар телендәге) әдәбият» предметларыннан үрнәк белем бирү программалары эшләнде. Туган (татар) тел, туган (татар) татар әдәбиятыннан, рус телендә

гомуми белем бирү оешмаларының татар телен өйрәнүче укучылары өчен яңа буын укыту-методик комплектлары төзелә, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары өчен татар теле һәм әдәбиятыннан видеодәресләр булдыру юнәлешендә проект гамәлгә ашырыла.

Соңгы берничә дистә ел дәвамында татар телен саклау, үстерү юнәлешендә төрле чаралар уздырыла, проектлар тормышка ашырыла. Заманча укыту чаралары булдыру юнәлеше дә игътибардан читтә калмый. 2013 елдан «Ана теле» онлайн-мәктәбе эшли. 2021–2022 уку елыннан Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларында СберКласс белем бирү платформасы файдаланыла. Татарстан Республикасында рус, татар һәм инглиз телләрендә укыта торган полилингваль белем бирү комплекслары ачылу – белем һәм тәрбия бирү юнәлешендәге зур казанышларның берсе.

Укучылар, укытучылар өчен төрле конкурслар, олимпиадалар, конференцияләр уздырыла. «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» россиякүләм бәйгесе, «Туган тел» бөтенроссия укытучылар бәйгесе, татар теленнән һәм татар әдәбиятыннан республика олимпиадалары, «Илһам» бөтенроссия яшь язучылар бәйгесе, «Каурый каләм» бөтенроссия конкурсы һәм башкалар шундыйлардан.

Шулай итеп, татарларда мәгариф системасы һәм тел белеме өлкәсендәге эшчәнлекнең күпгасырлык тарихы бар. Югарыда санап үтелгән уку йортларында шактый еллар дәвамында милли кадрлар әзерләү эше, татар теле өлкәсендә фәнни хезмәтләр язу, диссертацияләр яклау уңышлы башкарылып килде. Моннан тыш, төрле елларда Ульяновск, Ижевск, Мәскәү шәһәрләрендәге югары белем бирү оешмаларында да татар теле һәм әдәбиятыннан белгечләр әзерләнде.

Милли кыйммәтләргә йөз тотып, гасырлардан гасырларга килгән традицияләргә тугрылык саклаган хәлдә, заман таләпләренә җавап бирерлек белем һәм тәрбия бирү – бүгенге милли мәгариф системасы алдында торган бурычларның берсе. Югары уку йортларында татар мәктәпләре өчен мөгаллимнәр әзерләү юнәлешендә максатчан эш алып бару, белем бирүдә фәнни-методик нигезнең нык булуы һәм аның һәрдаим камилләштерелеп торуы, яңа технологияләр кулланып эшләү өчен тиешле шартлар тудыру – әлеге юнәлештә нәтиҗәле эш алып баруның төп алшартлары менә шулар.

Бүгенге көндә Татарстанда татар телен саклау һәм үстерү юнәлешендә шактый зур эш алып барыла. Татар теленең Татарстан Республикасы дәүләт теле статусына ия булуы, тиешле норматив-хокукый база булдырылу, максатчан дәүләт программалары кабул ителү һәм гамәлгә ашырылу шуны раслый, Татарстанда гына түгел, аннан читтә яшәүче милләттәшләребез өчен дә мөмкинлекләрне сизелерлек киңәйтә.

Әлеге эшчәнлек беренче чиратта мәдәният һәм мәгариф өлкәләрендә чагылыш таба. Бүгенге көндә татар телен – туган тел һәм Татарстанның дәүләт теле буларак өйрәтүнең фәнни-методик базасын яңарту, заманча технологияләр кулланып эш итү өчен шартлар тудыру юнәлешендә эш бара. Мәдәният өлкәсендә татар халкының телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклап калу һәм үстерүгә юнәлтелгән проектларны гамәлгә ашыруга зур игътибар бирелә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасында татар теленең гамәли кулланылыш даирәсен башка өлкәләрдә дә киңәйтү әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып кала.

# ЙОМГАК

Татар теле – бай тарихи юл үткән, озын гомерле телләрнең берсе. Аның төрки гаиләдәге язма традициясе VI–VIII гасырлардан ук килә. Иске татар әдәби телен башка төрки әдәби телләрдән аерып торган лексик, фонетик һәм грамматик нормалар исә XV–XVI гасырларда калыплаша. XVIII йөз ахыры –XX йөз башында милли әдәби тел формалаша. Ул, нигездә, татар теленең диалектлары катнашында хасил була. Татар теленең диалектлары үзләре дә милли телнең аерылгысыз бер өлешен тәшкил итәләр. Шулай итеп, хәзерге татар теле, күп гасырлар дәвамында үзгәрешләр кичерә, үсә, камилләшә барып, бүген без белгән һәм без аралаша торган тел булып җитешә. Татар телен камил белү төрки телләр гаиләсенә кергән башка тугандаш халыклар белән иркен аралашу мөмкинлеген бирә.

Әдәби тел бердәм нормаларга буйсына. Ул орфография, орфоэпиядә ачык гәүдәләнә. Телнең әдәби нормаларны куллану үзенчәлекләре белән аерылып торган стильләре дә формалашкан. Аларга матур әдәбият, иҗтимагый-публицистик, фәнни, рәсми канцелярия стильләре керә. Сүзлек составы ягыннан да тел гаять төрле булуы белән характерлана.

Тел һәрдаим хәрәкәттә, чөнки ул – тере тел. Телне кулланучылар булганда, ул туктаусыз үсеп-үзгәреп торачак. Шул рәвешле теге яки бу телдә сөйләшүчеләрнең булуы телне саклау һәм баету мөмкинлегенең төп шартларыннан берсе санала, чөнки телне саклау ул – милләтне саклау, дигән сүз. Әлбәттә, татар телен үстердә милли матбугат, матур әдәбият һәм милли мәгариф, тел белеме өлкәсендәге эшчәнлек зур роль уйный. Күпгасырлык тарихы булган мәгариф системасы бу эшне милли тәрбия бирү, милләт бөтенлеген кайгырту, халыкның тарихи хәтерен һәм рухи кыйммәтләрен

саклау белән бәйләп алып бара. Фән яңа технологияләрне дә шул максатка хезмәт итүгә җайлаштыра: татар телен өйрәнүдә, татарча аралашуны саклауда электрон, онлайн формат мөмкинлекләрен арттыру юнәлешендә эшли. Телне саклау, үстерү өлкәсендәге киң колачлы хезмәтләрнең дәүләт законы һәм дәүләт программалары кысаларында башкарылуы аларның зур әһәмияткә ия булуын ассызыклый.

Гомумән, борынгыдан килгән тел дигән асыл хәзинәне югалмау, аны киләчәк буыннарга камил хәлдә тапшыру халкыбыз алдындагы мөһим бурычлардан санала.

## Файдаланылган әдәбият


*Бакиров М.Х.* Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. 343 б.

*Галиуллина Г.Р.* Хәзерге татар теле лексикологиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2013. 123 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Чал татар әдәбиятының 100 елы // Казан утлары. 2020. № 5. Б. 72–76; 138–149; 174–181.

*Катанов Н.Ф.* Образцы книжной и устной литературы казанских татар. Материалы к изучению Казанско-татарского наречия. Ч. 1. Казань: Тип. Имп. ун-та, 1898. 168 с.

*Кукляшев С.Б.* Татарская хрестоматия. Казань: Тип. Имп. ун-та, 1859. 126 с.

*Курбатов Х.Р.* Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. Казан: Татар.кит. нәшр., 1999. 139 б.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1951. 452 с.

*Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарского языка). М.: Наука, 1978. 271 с.

*Ногман М.* XVII–XVIII йөзләрдәге русча-татарча кулъязма сүзлекләр. Казан: КДУ нәшр., 1969. 112 б.

*Рамазанова Д.Б.* Мишәр диалекты // Татар халык сөйләшләре: ике китапта. Икенче китап. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 4–11.

*Рамазанова Д.Б.* Урта диалект // Татар халык сөйләшләре: ике китапта. Беренче китап. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 19–22.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология: югары уку йортлары студентлары өчен. Казан: Хәтер, 1999. 288 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р.Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / фәнни мөх. Х.Й. Миңнегулов. 2014. 471 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда/ төз. Р. Рахмани Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар / фәнни мөх. М.Х. Бакиров. 2014. 415 б.

Татар грамматикасы. Өч томда. Т. I / ред. колл. М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, К.З. Зиннәтуллина. Мәскәү: Инсан; Казан: Фикер, 1998. 283 б.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 512 б.

Татар дөньясы=Татарский мир / авт.-төз.: Г.Ф. Габдрахманова, Э.М. Галимова, Д.Ф. Заһидуллина, И.Л. Измайлов, А.Р. Салихова, А.Г. Ситдыйков, Л.М. Шкляева. Казан: Заман, 2019. 392 с.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.

*Тенишев Э.Р.* О языке поэмы «Кыссаи Йусуф» Кул Гали // Поэт гуманист К. Гали. Казань, 1987. С.133–143.

*Хаков В.Х.* Тел – тарих көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 293 б.

*Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – нач. XVIII вв.). Казань, 1999. 408 с.

http://tatar-congress.org/ru/yanalyklar/vasil-shayhraziev-nasha-zadacha-obedinyat-i-pooshryat-vse-8-millionov-tatar

http://www.gks.ru/free_doc/new_site/perepis2010/perepis_itogi1612.htm

http://www.gks.ru/free_doc/new_site/population/demo/perepis_krim/perepis_krim.html

https://news.un.org/ru/story/2019/02/1348292

https://www.ethnologue.com/guides/how-many-languages-endangered

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
I БҮЛЕК. ТАТАРЛАРДА ЯЗУ ҺӘМ ӘДӘБИ ТЕЛ ТАРИХЫ . . . 7
Татарларда язу тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Татарларда әдәби тел тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Стильләр тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
II БҮЛЕК. ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ДИАЛЕКТЛАРЫ . . . . . . . . . 27
Татар теленең диалектлары һәм сөйләшләре . . . . . . . . 27
Татар теле диалектларының үзенчәлекләре . . . . . . . . . 32
III БҮЛЕК. ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ . . . . . . . . . . 38
Татар теленең нормалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Татар телендә сүзлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
IV БҮЛЕК. ТЕЛЛӘРНЕ САКЛАУ МӘСЬӘЛӘСЕ . . . . . . . . 54
Татарларда мәгариф системасы һәм тел белеме
өлкәсендәге эшчәнлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Йомгак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Файдаланылган әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69

Научно-популярное издание

**ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК: ПРОШЛОЕ И НАСТОЯЩЕЕ**

На татарском языке

Редактор: *Л.Г. Шарифуллина*
Компьютерная верстка: *Н.Т. Абдуллина*
Дизайн обложки: *А.В. Булатов*

Подписано в печать 20.09.2021.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная.
Усл.-печ. л. 4,2. Уч.-изд. л. 3,5. Тираж 3000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20